КЕЧКЕНӘ АВЫЛЛАР: бәйрәмсез калган юк

> 5

ХУШ КИЛӘСЕҢ, 2022! Яңа елга фаразлар сорауларга ачыклык кертте

> 16

ГҮЗӘЛ СӘГЫЙТОВА: «Бу ел мине көчле булырга өйрәтте»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 191 (28773) | Пәнҗешәмбе | 30 декабрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Аделина БИККИНИНА

СЫНАЛДЫК, СЫНАТМАДЫК

ЕЛГА ЙОМГАК ЯСЫЙБЫЗ

Үтеп баручы ел беркемгә дә җиңел булмады. Сәламәтлегебез – пандемия, рухыбыз – җанисәптә, сабырлыгыбыз – югалтулар, табигатебез корылык белән сыналды. Ел азагында һәрберебез нинди дер нәтиҗә ясагандыр, алдагы елга максатлар куйгандыр. Ә сезнең елниләр белән истә калды? Киләсе елга нинди нәтиҗә, кәефләр белән аяк басасыз?

> 6-7

СӘЛАМӘТЛЕК, БӘХЕТ ҺӘМ ИМИНЛЕК АЛЫП КИЛСЕН!

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Яңа ел МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле ватандашлар!

Сезне чын күңелдән якынлашып килүче Яңа ел белән котлыйм!

Бу бәйрәм, гадәттәгечә, безнең иң якты өметләребезне һәм могҗизалар көтүне, оптимизм һәм киләчәккә ышанычыбызны гәүдәләндерә. Без нәтиҗәләр ясыйбыз һәм яңа планнар корабыз.

Узып баручы елда икътисадның уңышлы үсеше нәтиҗәсендә без мөһим инфраструктура проектларын гамәлгә ашырдык, яңа торак, мәктәпләр, балалар бакчалары һәм башка социаль-мәдәни объектлар төзүне дәвам иттек. Социаль программаларны тормышка ашыру Татарстанда яшәү, уку һәм эш шартларын тагын да яхшыртты.

Без медицина хезмәткәрләренә рәхмәтле – аларның фидакарь хезмәте һәм эпидемиягә каршы күрелгән чаралар халәне тотрыкландыру мөмкинлеге бирде. Республика волонтерлары авыр минутларда кешелеклелек, миһербанлылык һәм игелеклелек кебек күркәм сыйфатларга ия булуларын күрсәттеләр, мохтаҗларга ярдәм иттеләр.

Татарстанлыларның күбесе Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар барышында Татарстан Республикасының динамик үсеше, Россия куәтен ныгыту юнәлешен хуплады.

Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында күпсанлы проектлар һәм чаралар тормышка ашырылды. Бу республикада милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны ныгытуга зур өлеш кертте.

Киләсе 2022 нче елны без Цифрлаштыру елы дип игълан иттек. Ул цифрлы икътисадның алга таба үстерүгә, күрсәтелә торган хезмәтләрнең үтемлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән технологияләрне һәм сервисларны камилләштерүгә ярдәм итәр дип ышанам.

Кадерле татарстанлылар! Яңа ел барыбыз өчен дә уңышлы булсын, һәр йортка сәламәтлек, бәхет һәм иминлек алып килсен!

Яңа 2022 нче ел белән!

Районнарда ни хәлләр?

Түбән Кама

Илья Матюшенцев һәм Владимир Конюховны Татарстан Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Мактау грамотасы һәм 25 мең сум күләмендә акчалата премия белән бүләкләделәр. 29 июньдә Иске Чишмә авылындагы бер шәхси йортта янгын чыга. Ут санаулы минутлар эчендә бөтен йортны биләп ала. Хуҗа кеше янгын турында хәбәр итүче җайланма тавышын ишетә, ләкин өйдән чыгып китәргә өлгерми. Кыю йөрәкле ике егет, ут эченә кереп, ике кешенең гомерен саклап кала. «Бер-береңә ярдәм итү гадәти күренеш дип уйлыйм. Минем урында башка берәр кеше булса да, шулай эшләр иде», – ди Илья Матюшенцев. Моңа кадәр Илья биолог булырга теләгән. Хәзер исә аны башка һөнәр – коткаручы булу кызыксындыра. Бүген менә шуның өчен ныклап имтиханнарга әзерләнә егет. (e-nkama.ru)

Арча

Районда 90 нчы мәчет ачылды. Яңа гыйбадәтханә Иске Иябаш авылында урнашкан. Аңа 2020 елның 28 июнендә нигез салынган иде. Ул авыл халкының һәм иганәчеләрнең матди ярдәме белән төзелде. Мәчетнең гыйбадәт залы 100 квадрат метр һәм ул үзенә берьюлы 70–100 кешене сыйдыра ала. 2021 елда Татарстанда барлыгы 16 мәчет ачылды. Аларның 12се – яңа, 4есе исә төзекләндерүдән соң кабат ачылды. Алар Кукмара, Мөслим, Алабуга, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Саба, Балык Бистәсе, Сарман, Арча, Буа, Азнакай, Чүпрәле һәм Чирмешән районнарында урнашкан. (Татарстан Диния нәзарәтенең матбугат хезмәте)

Мамадыш

Югары Ушма авылы китапханәчесе Фәнзилә Шәрәфетдинова «Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрендәге иң яхшы нәшрият проекты» юнәлеше буенча «Онытырга хакыбыз юк» исемле китап чыгаруга Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең 500 мең сум күләмендәге грантын отты. Китапта авыл җирлегендә яшәгән кешеләрнең Бөек Ватан сугышы чорында ил белән бергә күтәргән авырлыклары, Бөек Җиңүгә керткән өлеше турында языла. Истәлекләр мәктәп балалары, укытучылар, китапханәчеләр, ветераннарның балалары яки оныклары сөйләгәннәрдән язып алынган.
(«Нократ»)

Нурлат

Район үзәгендә журналистларга һәйкәл ачтылар. Ул Нурлаттагы «Дуслык» скверында урнашкан. Журналистларга һәйкәл ачу тәкъдимен «Нурлат-информ» агентлыгы җитәкчесе Резеда Гиняева җиткергән иде. Ачылыш тантанасында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, Нурлат районы башлыгы Алмаз Әхмәтшин, Дәүләт Советы депутатлары Рәис Сөләйманов, Людмила Рыбакова, Шамил Яһудин, «Татмедиа» АҖ медиадиректоры Әлфия Әдиятова һәм башка кунаклар катнашты.
(«Нурлат-информ»)

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

РӘХМӘТ ӘЙТҮ ӨЧЕН МӨМКИНЛЕК

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ ИҢ ЯХШЫ ҖИТӘКЧЕЛӘРНЕ БҮЛӘКЛӘДЕ

Иң яхшыларын ел азагында барлыйлар. Татарстан Президенты елдагыча «Ел җитәкчесе – 2021» республика конкурсы җиңүчеләрен бүләкләде. Тантанада узып баручы елга йомгак ясалды, 2022 елга бурыч-максатлар билгеләнде, рәхмәт сүзләре яңгырады.

– Яңа ел алдыннан без гадәттәгечә республиканың алдынгы предприятие-оешма җитәкчеләре, хакимият һәм җәмәгатьчелек вәкилләре белән очрашабыз, «Ел җитәкчесе» конкурсына йомгак ясыйбыз. Бу – хезмәт коллективларына һәм аларның җитәкчеләренә Татарстан икътисадына керткән өлешләре өчен рәхмәт белдерергә яхшы мөмкинлек. Әлеге конкурс 21 нче тапкыр үткәрелә, – диде Рөстәм Миңнеханов, бәйрәм кунакларын сәламләп.

Пандемия бөтен тармакларга да үз үзгәрешләрен кертте, шунлыктан да елның катлаулы булуын билгеләп үтте Президент.

– Төп бурычыбыз – кешеләрнең сәламәтлеген һәм иминлеген саклау. Медицина хезмәткәрләренә фидакарь хезмәтләре, предприятие җитәкчеләренә – куркынычсызлык чараларын тәэмин итүләре һәм вакцина ясатуны оештыруда ярдәмләшүләре өчен рәхмәт белдерәсем килә. Авырлыкларга карамастан, төп юнәлешләр буенча күрсәткечләребезне яхшырта алдык, – диде республика җитәкчесе.

Рөстәм Миңнеханов Россия Президенты Владимир Путинга күпбалалы һәм аз керемле гаиләләргә, пенсионерларга, икътисад тармакларына, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлеккә кирәкле вакытта ярдәм күрсәтүләре өчен рәхмәтен җиткерде.

Республика җитәкчесе әйтүенчә, икътисади күрсәткечләрнең тотрыклы үсеше нефть, газ, химия комплексы, машина төзелеше, энергетика, төзелеш тармаклары бәрабәренә ирешелә. Шул ук вакытта ТОСЭР, «Алабуга» махсус икътисади зонасы, «Иннополис», индустриаль һәм сәнәгать мәйданчыкларында тормышка ашырылучы инвестиция программалары да моңа ярдәм итә.

– Залда тармак ветераннары да бар. Нәкъ менә сезнең куллагыз белән сәнәгать предприятиеләренә нигез салынды. Татарстан икътисады үсешенә керткән шәхси өлешегез өчен сезгә аерым рәхмәт, – диде Рөстәм Миңнеханов.

«Ел җитәкчесе – 2021» конкурсы нәтиҗәләре хакында исә Премьер-министр Алексей Песошин сөйләде. «Катнашучылар исемлеге республика министрлыклары һәм ведомстволары, шәһәр һәм район, эш бирүчеләр берләшмәләре һәм профсоюзлар федерациясе тәкъдимнәре нигезендә төзелде. Бу конкурста катнашучылар саны ел саен арта бара. Быел конкурска барлыгы 120 җитәкче тәкъдим ителде. Конкурста 97 җитәкче номинант булды», – диде ул. Җиңүчеләр рәтендә «Татнефть», «Татэнерго», Кама фәнни-техник үзәге, «Радиоприбор» җәмгыяте, «Сетевая компания» һәм башка зур оешма вәкилләре бар.

КАЗАНСУНЫ ҺАВАДАН КИЧӘСЕ

Ният

Казанда асылма юл төзергә ниятлиләр. Шәһәр үзәгендәге Горький исемендәге парк белән «Ак барс Арена» стадионын тоташтырачак проект 3 млрд сумга төшәчәк. Бу һәм тагын 5 проектны Президент Рөстәм Миңнеханов уздырган Инвестицион совет утырышында карадылар.

tatarstan.ru

«АэроМост» компаниясе генераль директоры Денис Белов әйтүенчә, элмәле юлның озынлыгы 2773 метр булачак. «Ул Рус – Алман Швейцариясенең парк зонасы аша узачак һәм яшел шәһәр зоналарына искиткеч күренеш ачачак», – дип ышандырды Денис Белов. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, әлеге проект шәһәргә кирәк һәм аның турында фикер алышу күптән бара инде. Ул «Урам» экстрим паркы һәм Горький исемендәге парк тирәсендәге мәйданнарны берләштерәчәк.

Чаллының 67 нче микрорайонында исә балалар бакчасы төзергә җыеналар. Кала мэры Наил Мәһдиев мондый социаль мөһим проектларны гамәлгә ашыруга әзер булуын әйтте. Рөстәм Миңнеханов проектны хуплады һәм аны мөмкин кадәр тизрәк гамәлгә ашырырга кушты.

Югары Ослан районында күзәтү манарасын төзергә планлаштыралар. «Фалкон Девелопмент» компаниясе вәкилләре әйтүенчә, 30 метр биеклектәге корылманы төзү 50 млн сумга төшәр дип көтелә. Рөстәм Миңнеханов бу эш өчен урын әзерләргә, шулай ук проект турында мәгълүмат бирергә кирәклеген әйтте.

Яшел Үзән районында берьюлы ике проектны тормышка ашыру нияте бар. Беренчесе – «Зеленодольск 3» күпләп сату-бүлү үзәге. Проектның максаты – зур габаритлы йөкләрне саклау һәм эшкәртү өчен мәйданчык оештыру. Аны тормышка ашыру өчен 1,88 млрд сум күләмендә инвестиция кирәк. Нәтиҗәдә 1000нән артык кешегә эш урыны булачак. «Транзит-Сити» компаниясе исә күпфункцияле зур автокомплекс төзергә тәкъдим итте. Биредә зур тоннажлы автомобильләргә хезмәт күрсәтергә ниятлиләр. Президент ике проектны да хуплады һәм аларның файдалы буласын әйтте.

КЕМГӘ – ЯЛ, КЕМГӘ – ЭШ

МИНИСТРЛЫКЛАР БӘЙРӘМДӘ ЯХШЫ ҺАВА ТОРЫШЫ КӨТӘ

«ВТ» архивыннан

Бәйрәм көннәрендә юллар һәм ишегалларын чиста тотарга, ул-бу килеп чыкса, чарасын тиз күрергә тырышачаклар. Хөкүмәт йортында узган очрашуда транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов белән төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары Алексей Фролов әнә шулай дип вәгъдә бирделәр.

Бу көннәрдә Казан «бөке»дә утыра. Бәйрәм ыгы-зыгысына кар да өстәлгәч, барасы җиреңә тиз генә барып җитеп булмый. Транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов әйтүенчә, алар юлдагы хәлләрне күзәтеп тора. Бәйрәм көннәрендә дә шулай булачак. Юл өчен җаваплы оешмалар гадәти режимда эшләячәк, техника да әзер торачак.

Министр юлларны һәрдаим чистартып һәм тиешле катнашмалар сибеп торасыларын әйтте. Республикада 83 мең тонна техник тоз, 257 мең тонна ком әзерләнгән. Федераль юллар өчен 109 мең тонна ком һәм 27 мең тонна реагент хәстәрләп куелган.

– Без нинди һава шартлары булса, шуңа әзер. Юл хуҗалыгы оешмалары карамагында 1140 берәмлек техника бар. Алар кар да чистарта, юлга катнашма да сибә. Тимер юлларны кардан арындыра торган машиналар да әзер. Аэропортта да кышкы режимга күчеп эшлиләр. Анда да кирәкле техникалар җитәрлек. Безнең тармакта әллә ни проблемалар бар дип әйтә алмыйм. Без әзер. Хәзер бар да һава торышыннан торачак, – диде министр.

– Республика юлларында туктап җылынырга өчен 54 урын бар. Юлда күңелсезлекләр булганда, ягулык салу станцияләре дә, кунакханәләр дә ярдәмгә киләчәк. Әмма мин республика халкыннан һава торышының нинди буласын белмичә, юлга чыкмауларын сорар идем. Әгәр инде каядыр юл тотасыз икән, үзегез белән термоста кайнар чәй алыгыз. Элемтәсез калмагыз. Юлда туктап калган кешеләрне күрсәгез, ярдәм итегез.

Фәрит Хәнифов сүзләренчә, балаларны йөртүче автобуслар игътибар үзәгендә булачак.

– Республикадагы мәктәп автобуслары ГЛОНАСС системасы белән тәэмин ителгән. Балаларны каядыр алып барырга уйлаганда, тиешле урыннарга хәбәр итсеннәр иде. Ул автобуслар онлайн режимда күзәтелә. Әгәр берничә автобус юлга чыга икән, аларны ГИБДД хезмәткәрләре озата, – диде ул.

Бар да тыныч кына, артык мәшәкатьсез узсын иде, диючеләр арасында торак-коммуналь хуҗалык тармагы да бар. Алар өчен бу көннәрдә ял юк.

– Һәр бәйрәм көненә җаваплы кешеләр билгеләнгән. Без барлык районнар, оешмалар, тармак министрлыклары белән элемтәдә торачакбыз. Торак-коммуналь хуҗалык тармагына бәйрәм көннәрендә эшләү өчен барлык шартлар да бар, – диде төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары Алексей Фролов.

– Бәйрәм көннәрендә күпләр ял итә. Шунлыктан өйдә торучылар арта. Димәк, бәйрәм арты көннәрендә 2, 3 тыйнварда чүп контейнерлары тулачак. Аларны вакытында алып чыгуны тәэмин итәбез. Тик чүп мәйданчыкларына керү юлларын чистартып торырга кирәк булачак, – ди Алексей Фролов.

Карны да көрәргә кирәк. Көрәге булса да, бу эшне башкару җиңел түгел. Беренчедән, урам җыештыручылар җитми. Икенчедән, шәһәр ишегаллары машина белән тулган. Ә бәйрәм вакытында кешене урыныннан кузгату җиңел түгел. Министр урынбасары әнә шуннан да зарланып алды.

Әле бит кар белән чүп кенә түгел, кайдадыр су торбасы, кайдадыр җылылыкныкы шартларга мөмкин. Министр урынбасары, нинди генә хәл булмасын, әзер икәнлекләрен әйтә. Алар алдан хәстәрен күргән. «Татлизинг» оешмасы базасында кирәк-яраклар әзерләнеп куелган.

– Торбалар да катып китә. Аварияләр дә булгалый. Әмма безнең хезмәткәрләр аларны тиз арада төзекләндерергә өйрәнде инде. Бездә запас җиһазлар да әзер. Махсус техника, генераторларны барлап куйдык. Шулар өстенә, җитди авария булса дип, ике күчмә котельныйны да әзерләдек. Өйрәнүләр дә уздырдык. Әмма алары кирәк булмас дип өметләнәбез, – диде ул.

Сүз уңаеннан, юллар буенча хәбәрегез бар икән, аны министрлыкка **8(843) 291-91-91, 8 (843) 291-90-13** телефоннары буенча шалтыратып җиткерә аласыз. Торак-коммуналь хуҗалык буенча диспетчер үзәгенә **8(843) 231-14-10** телефон номеры аша мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

БӘЙРӘМ БЕЛӘН!

Хөрмәтле иптәшләр, кадерле татарстанлылар!

Татарстан Республикасы коммунистлары, ТР Дәүләт Советындагы КПРФ фракциясе исеменнән һәм шәхсән үзем Сезне якынлашып килүче Яңа ел белән чын күңелдән котлыйм!

2022 ел Сезгә тынычлык, иминлек һәм уңышлар гына алып килсен, менә дигән якты идеяләр бүләк итсен һәм аларны тормышка ашырырга да булышсын! Юлыгызда кыенлыклар очрый калса, алар җиңел генә узып китәрлек булсын!

Яңа ел сезгә уңышлар, бәхет, иминлек, ныклы сәламәтлек, җан җылысы алып килсен! Киләчәк тормышыбыз ышанычлы, көчле, гадел, социалистик булыр дип ышанып калам.

Хафиз МИРГАЛИМОВ,
республика комитетының беренче секретаре,
ТР Дәүләт Советында
КПРФ фракциясе җитәкчесе

Айдар ШӘЙХИН

Күк йөзендә ниләр бар?

Татар телендә, башка төрки телләрдә кебек үк, күк җисемнәрен атый торган, әмма соңрак грек-латин сүзләренә алыштырылган төшенчәләр бар. Алар – телебезнең аеруча кадерле хәзинәсе, күрке. Кайберләрен искә төшерергә һәм, сүз байлыгыбызны арттырып, аңа күркәм төсмерләр биреп, көндәлектә куллана башларга тәкъдим итәм.

Венера Чулпан Таң йолдызы

Төнге күк йөзендә татарга иң якын булган җисем – Венера планетасы. Телебездә аның *Чулпан йолдыз* исемле атамасы бар. Әлбәттә, Венера йолдыз түгел, әмма төрки-татар аңында ул планета дип тә аталмаган. Атаклы белгеч, «Миллият сүзлеге»н төзүче Адлер Тимергалин, шәркыят белгече Алим Гафуровка таянып, *чулпан* сүзенең гомумән якты йолдызларны аңлаткан булырга мөмкинлеген хәбәр итә. Һәрхәлдә, бу сүз бик борынгы һәм ул төрки телләрнең күпчелегендә очрый. Ул фарсы теленнән дә кергән булырга мөмкин, моңа да җитди дәлилләр бар. Әмма төркиләргә бу сүз бик якын һәм кадерле инде. Нәби Дәүли сүзләренә язылган, Илһам Шакиров яратып башкарган «Чулпан» җырында Венера планетасының күк йөзендә хәрәкәте тасвирлана:

«Шул чакта Кояш ал йөзен ачты,
Чулпан кызарды, аннан соң качты».

Чыннан да, Венера планетасы, бигрәк тә кышкы вакытларда, күк йөзендә Кояш чыкканын «көтеп утыра». Бу планетаның телебездә кулланылган башка атамалары – *Зөһрә йолдыз, Таң йолдызы*.

Ә менә *Кече Чулпан* дип Кояшка иң якын планетаны, ягъни Меркурийны атаганнар. Планеталарны стихияләр буенча бүлеп чыккан очракта (Кытай традициясенә ияреп), аны *Су йолдызы* дип әйткәннәр.

Дүртенче планета, ягъни Марс *Ут йолдыз, Мәррих, Бәһрам* дип аталган. Беренче сүзе төрки булса, калганнары – алынмалар. Иң зур планета Юпитерны *Мөштәри, Агач йолдыз* дисәләр, иң зур боҗралары булган Сатурн – *Зөхәл, Туфрак йолдыз* исемнәре белән йөргән. Адлер Тимергалин Сатурнның *Сәкәнтир* исемле варианты барлыгын да хәбәр итә.

Әлбәттә, бу сүзләрне хәзер телебездә киң куллану кирәк тә түгел. Әмма аларның кайчандыр кулланылганын белергә кирәк. Ни өченме? Татарларда фән, гыйлем, астрономия, физика, химия кебек фәннәр булганмы, бу өлкәләр турында татарча сөйләшеп буламы-юкмы дигән мәгънәсез сорауларга урын калмасын өчен кирәк бу.

Планета Сәйярә

Планета сүзенең үзен татарчалаштырып буламы соң? Әлеге грек сүзе «дөнья гизүче» дигәнне аңлата. Шул этимологиядән чыгыптыр, күрәсең, гарәп телендә һәм аннан соң төрки-татар традициясендә шул ук мәгънәдә *сәйярә* сүзе кулланылган. *Сәйярә* – планета, димәк.

Спутник сүзен *юлдаш* дип тә, *иярчен* дип тә тәрҗемә итәргә була. Әмма фәнни әдәбиятта *иярчен* сүзе ешрак кулланыла. Бу миңа мантыйклырак булып тоела.

Созвездие сүзенең татар телендә кабул ителгән һәм дөрес булган тәрҗемәсе – йолдызлык (мәсәлән, *Аждаһа йолдызлыгы*). Әмма кайбер очракларда без йолдызлыкны да йолдыз дип кенә әйтәбез: *Җидегән йолдыз, Иләк йолдыз, Көянтә йолдыз* һ.б.

Билгеле ки, Кояш ел дәвамында уза торган хәрәкәте (эклиптика) юлында урнашкан 12 йолдызлыкны зодиак йолдызлыклары дип атыйлар. Аларның татарларда кулланылган атамалары турында Мәрҗани болай дип яза: *«хәмәл, сәвер, җәүза, саратан, әсәд, сөнбелә, мизан, гакрәб, кавыс, җәди, дәлү, хут» дип, гарәби исемнәр кулланалар».*

Хәлбуки хәзер безнең телдә кулланыла торган *Кучкар, Үгезбозау, Игезәкләр, Кысла, Арыслан, Кыз (Сөмбелә), Үлчәү, Чаян, Укчы, Кәҗәмөгез, Сукояр, Балык* атамалары бик урынлы һәм дөрес яңгырый.

Әйтеп кенә бактым

Тәрбия

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

1956 елда Яңа елны беренче сыйныф укучысы буларак каршы алдым. Чыршы бәйрәмендә катнашучы һәр бала үзенә битлек әзерли, кемдер булып киенә һәм бәйге игълан ителеп, танымаслык булып киенүчегә бүләк тапшыралар иде. Ә укытучы апа миңа баш катырмаска кушты. «Син «Иске ел» булачаксың, киемне үзебез әзерлибез», – диде.

Килеп җитте бу көн. Миңа ак ситсыдан тегелгән күлмәк-ыштан бирделәр, башка бүрек сыман бер нәрсә киерттеләр. «Иске ел» икәнем күренеп торсын өчен, күлмәккә «1956 ел» дигән язулы чүпрәк тегелгән иде. Классташым – «Яңа ел»ның да киеме әллә ни түгел иде, тик менә күкрәгенә «Яңа ел» дип язылган. Мин шуңа үрсәләндем, нигә әле мин түгел, ә укытучы Мансур абый малае Илһам «Яңа ел» булырга тиеш?

Укытучыма үпкәләп маташтым. Ә ул: «Риман энем, Илһамның «бишле» билгеләре синекеннән күбрәк, шуңа күрә аны Яңа ел иттек», – дип, мине тынычландырырга тырышты. Укытучы апай әйткәч, берни дә эшләп булмый бит инде, ризалашырга туры килде. Әмма үпкә дигәннәре шактый озак дәвам итте. Ел буе көткән Чыршы бәйрәмендә сиңа: «Хуш, Иске ел!» – дип әйтсеннәр дә уеннарга катнаштырмасыннар әле? Ә Илһамны: «Хуш киләсең, зарыгып көтелгән Яңа ел, түргә уз! Төкле аягың белән!» – дип каршы алдылар һәм ул бәйрәмнең күркенә әйләнде дә куйды. Кыш бабай һәм Кар кызы белән кулга-кул тотынышып, чыршы тирәсендә дә әйләнде, ниндидер бүләкләр дә алды. Дөрес, мине Чыршы бәйрәменнән куып чыгармадылар, әмма сценарий буенча миңа нидер сөйләү, эшләү каралмаган иде, кем әйтмешли, аяк арасында буталып йөрдем инде шунда. Әле җитмәсә, кайбер усал теләләр: «Син китмәдеңмени әле?» – дип тә төрттергәләделәр.

Бу вакыйгага инде 65 ел вакыт узган. Үпкә дигәннәре әллә кайчан юкка чыгып, күңелдә балачакны сагыну хисләре генә калган. Шуларга өстәп, кара әле, безне ничек тәрбияләгәннәр икән бит, дип тә уйлап куясың. Мин, Илһамнан калышмаска теләп, тагын да тырышып укый башлаганмын. Әле елка бизәүне дә иң яхшы укучыларга тапшыралар иде, ә уенчыкларны да, нигездә, үзебез ясадык. Монысы да үзенә күрә бер тәрбия чарасы булган бит! Укытучыларыбыз арасында югары уку йортларын тәмамлаганнар юк иде. Кайберләре нибары җиде класс белемле. Дөрес, тора-бара алар урта белем алдылар, читтән торып югары уку йортларын тәмамладылар һәм укыту-тәрбия эшен фәнни нигездә алып бара башладылар. Ә аңа хәтле без остазларыбыз җитәкчелегендә «тормыш мәктәбе» узганбыз булып чыга. Өлкәннәргә хөрмәт-ихтирам хисләрен дә үзләре үрнәгендә тәрбияләгәннәр.

Мәктәп бакчасында һәр классның үз тәҗрибә участогы бар иде, анда «фән казанышлары»н кулланып, яшелчә, җиләк-җимеш үстердек, һәр класс, чиратлашып, мәктәп өчен кышлык утын әзерләде. Һәр класс, чиратлашып, мәктәп куяннарын карады. Болары хезмәт тәрбиясе иде. Без зур эшләргә кумәкләшеп тотынырга өйрәндек.

Язганнарымнан, әлбәттә, консерватизм исе аңкыйдыр, алар кайберәүләр өчен акыят, хәтта көлке тоелыр. Миннән: «Заманнан артта калгансың, Риман бабай», – дип көләрләр.

Килешәм, бүгенге тормыш бөтенләй башка һәм үткәнне сагынып үткәрүдән мәгънә юк кебек. Шул ук вакытта яшьтән хезмәткә өйрәнү, ярдәмләшеп яшәү, өлкән буынга һәм үткәннәргә хөрмәт белән карау – берсе дә мәгънәсез нәрсәләр түгелдер дип уйлыйм.

КЕМНӘР БЕЗ?

ЯКИ КЕШЕ ТОРМЫШЫНА ФИЗИКА ҺӘМ ГЕНЕТИКА КҮЗЛЕГЕННӘН КАРАШ

Сизәсезме: еллар ашкын тизлектә уза һәм без вакытның бәрәкәте югалудан зарланабыз. Барысы да әзсез үткән шикелле: кылган гамәлләр онытыла, сөйләгән сүзләр тишек иләктән коелган кебек төшеп кала, чәчләргә чал керә, сакаллар агара. Утыз-кырык ел вакыт узгач, без яшьлектәге танышларны танымыйбыз. Хәзерге егерме яшьлекләргә моны аңлату кыен, әмма елларның марафоны бик тиз үтә һәм алар да безнең кебек җыерчыклы йөз, салынкы иңнәр һәм бер бәйләм хроник чирләр белән бүләкләнә.

Яңа елны бәйрәм итеп каршыларга була, гадәттәге режим белән ятып йокласаң да берни дә оттырмыйсың (бу юлларның авторы, мәсәлән, шулай эшли), әмма ничек кенә кылансак та, асылда без картлыгыбызны каршылыйбыз, ашкынабыз икән, шуңа таба ашкынабыз. Менә аны бәйрәм итәргә кирәктерме, анысы һәркемнең тормышка карашына бәйле. Шушы урында тукталып, мин бераз үзебезнең тәнебезгә күз төшереп алырга чакырам. Бу тормыш бәйрәмендә без гаҗәеп катлаулы һәм хикмәтле төзелештәге тән белән бүләкләнгәнбез бит. Урта мәктәпне тәмамлаучылар хәзер яхшы белә: кеше тәне бик вак күзәнәкләрдән тора. Олы кешедәге күзәнәкләрнең санын галимнәр якынча 10ны 10ның унөченче дәрәҗәсенә тапкырлагач килеп чыга торган сан белән исәплиләр. Аңлашыла инде: бу санны бер артыннан нульләр тезеп язсак, газета бите сыйдырмаячак. Фәнни терминнарга бик кереп китмичә генә искә төшерәбез: күзәнәк үзе дә катлаулы төзелешле: аның тышчасы бар, төше бар, алардан тыш әле тагын аксым һәм липидлар җитештерә торган үз «фабрика»сы, энергия җитештерә торган «электр станциясе» белән тәэмин ителгән. Соңгысын митохондрия дип йөртәләр. Күзәнәкнең төше бик хикмәтле. Анда генетик мәгълүмат кодлар белән язылган. Без аларны ДНК молекулалары дип йөртәбез. Бер кеше тәнендәге ДНК молекулаларын (генетик информация йөртүче әйберләрне) сузсак, ди галимнәр, Җирдән Кояшка кадәрге арадан мең тапкырдан да озынрак килеп чыгар иде. Исегезгә төшерәм: Җирдән Кояшка кадәр якынча 150 миллион километр. Күзәнәк төшендә кешенең тышкы кыяфәте: чәчләрнең, күзләрнең төсе, борынның һәм башка әгъзаларның формасы, нинди чирләргә бирешә торган булуы, хәтта психикасы мәгълүмат итеп язылган. ДНК молекулаларының озынлыгын искә төшерсәк, моның бик катлаулы китап икәнен бераз аңлый алабыз инде.

Без ана карынында яралып үсә башлауга ук, шундый катлаулы «китап» белән бүләкләнәбез, һәм ул китап тормышыбызны билгели башлый. Әмма туып, якты дөньяда яши башлау белән ул «китап»ка без үзебез дә мәгълүмат тутырабыз: без сөйләшкән сүзләр, укыган китаплар, караган кинофильмнар, кылган гамәлләр котылгысыз рәвештә ДНКда язылып баралар, ди Омск физигы Виктор Ярцев. Гомумән, төрле тармак галимнәре, бер дә уйламыйча гына сөйләшеп, безнең үз тормышыбыз китабын яздырып барубызга аз гына да шикләнмиләр. Хәзерге фән бу хакта ачышларны кыю ясый. Компьютер дисклары, флешкалар, чиплар белән таныш булган заман кешесенә моны аңлау кыен түгелдер дип уйлыйк. Хәзер бит кибеткә кергәндә дә безнең турында мәгълүмат язылган куар-код сорыйлар. Бер-ике ел элек Владимир Путин чит ил разведкалары россиялеләрнең генетик мәгълүматын (биоматериалны) җыя дип әйткән иде. Кремль лидеры үзе дә күптән түгел генә ил халкының милли генетик мәгълүматы базасын булдырырга тәкъдим итте һәм «Роснефть» үзендә эшләүче йөз мең нефтьченең шундый мәгълүматын туплау эшенә керешәчәген дә белдерде. Менә ул базаның ни өчен кирәклеген без аңлап бетермибез, әмма генетик код бик кыйммәтле нәрсә һәм аны сакларга һәм камилләштерергә кирәк, монысы бәхәссез. Үз «китабыбыз»га яхшы мәгълүмат кына язабыз икән, отабыз, киресенчә булганда оттырабыз. Сөйләсәң, яхшы сүз генә сөйлә, уйласаң, яхшы уй гына уйла, кылсаң, гамәлнең изгесен кыл, дигән сүз бу. Мөселман мәзһәбенең башында торган имам Шәфигый, мәсәлән: «Үзеңә хәерлесен теләсәң, кешеләр турында яхшы уйла», – дип әллә ничә гасыр элек әйтеп калдырган. Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (салләллаһу вә галәйһи вә сәлләм) дә бу хакта бик күп мәшһүр хәдисләре бар. Әйтик, Ахырзаман илчесе гомерне озын итү һәм муллыкка ирешү өчен туганлык бәйләнешләрен сакларга һәм ныгытырга куша безгә.

Генетика һәм физика менә бу гамәл һәм гомер озынлыгы мәсьәләсенә ничек карый? Нобель премиясе лауреаты Элизабет Блэкберн, фәнни яктан күз ташлап, уйлаган уйларыбыз һәм кылган гамәлләребез гомеребезне кыскарта да, озынайта да ала, ди. Эш шунда: ДНК чылбырының очында фән теломер дип атаган саклагыч капкачка охшаган нәрсәләр бар. Яшәгән саен шул теломерлар кыскара һәм бервакыт алар тәмам кечерәеп, күзәнәк бүленүдән туктый. Теломерлар кыскарган саен, без картаябыз. Генетик мәгълүматта сиңа кайчан да булса йөрәк чире белән авыру язылган икән, ул да теломерлар билгеле бер күләмдә кыскаруга мәйданга чыга, дип раслый галим. «Теломерлар безне ишетә», – ди ул һәм начар уйлардан, сүзләрдән, гамәлләрдән безнең гомер дәвамлылыгын билгеләүче шул хикмәтле нәрсәләр кыскара да, озыная да алалар, ди. Ягъни «брат братның көтү көткәненә рад» дип яшисең икән, рәхим ит: теломерларны кыскарттың. Киресенчә, җылы туганлык хисләре белән янганда һәм кардәшеңне үзеңнән өстен күргәндә, ДНК чылбырын каплаган шул хикмәтле нәрсәләрне озынайттың һәм гомереңә дә күпмедер сузылды. Һәрбер уй, һәр гамәл, без караган кинолар һәм тапшырулар, спектакльләр, әйткән сүзләр теломерлар белән тыгыз бәйләнештә тора һәм гомеребезгә хәлиткеч йогынты ясый. Ашау-эчү, физик хәрәкәтләрнең дә тәэсире зур аларга. «Яшәү рәвеше теломерларның озынлыгына һәм, димәк, гомер озынлыгына йогынты ясый ала», – ди Гарвард генетигы Дэвид Синклер.

Нәтиҗә ясыйк әйдә: Яңа елны гына түгел, һәр туган таңны яхшы ниятләр белән каршылыйсың һәм көнне изге гамәлләр белән тәмамлыйсың икән, син күзәнәк дәрәҗәсендә яхшырдың: сәламәтлегең ныгыды, гомер озынлыгына уңай тәэсир иттең. Бар булмышың зарланудан, кешеләргә яманлык теләүдән һәм эшләүдән, көнчелектән торса, күзәнәк дәрәҗәсендә начарайдың һәм оттырдың. Аллаһы Тәгалә дә искәртә безгә бу хакта. Ибраһим сүрәсенең 7 аятендә (мәгънәсе): «Әгәр нигъмәтләремә шөкер итсәгез, нигъмәтләремне сезгә арттырырмын, әгәр көферлек кылсагыз, минем газабым бик каты», – ди. Сәламәтлек, гомер озынлыгы, рухи саулык – болар нигъмәтләр бит инде. Шуларның булган кадәресенә шөкер итеп, без аларның артуына ирешә алабыз, димәк, зарланып һәм көнчелек утында янып, газаптан башка бернигә дә ирешмибез. 2022 елга аяк басар алдыннан бу юлларның авторы шулар турында уйланды.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ТӘРӘЗӘҢДӘ УТЫҢ БАРМЫ?

Кечкенә авыллар тормышы турында газетабызда ел дәвамында язып бардык. Шунысы кызык: анда яшәүчеләрдән һич кенә дә моң-зарны ишетмисең. Алар саф һава, тәмле чишмә суын, күңел тынычлыгын барыннан өстен күреп, үз көйләренә яшәп ята. Яңа ел якынлашканда, шундый авылларда яшәүчеләрнең бәйрәм кәефен белештек. Бәйрәм көннәрен мич ягып, су ташып, кар көрәп кенә уздырмыйдыр бит инде алар?



Кышкы экстрим

Кукмара районының Тәмле Чишмә авылында Нурулла абый Гайфетдинов ялгызы гына яши. Хатыны Роза апа кышка шәһәрдәге фатирына китә. Хатынына бәлешләр пешереп ашата, күлмәкләр тегеп кидертә торган Нурулла абый бу! Өендәге урындыкларны да үзе ясаган. Без җәй килгәндә, җиңнәрен сызганып, мич чыгара иде. Нурулла абый белән элемтәгә керә алмадык. Аптырагач, бу авылда умарта тотучы, ә үзе Кукмарада көн күрүче Тәлгать абыйдан хәлен белештек.

– Нурулла абый бер дә тик тормый, сез аңа кич шалтыратыгыз. Кыш буе утын әзерләп, аны чана белән ташый. Кыскасы, урманнан кайтып керми. Авыл башындагы чишмәдән су алып кайта. Миченә ягасы, хуҗалыгын карыйсы бар, – ди Тәлгать Сөнгатуллин. – Кышы бер дә күңелсез үтми аның. Авылга атна саен карчанада йөрергә, текә таулардан мотоциклда төшәргә экстрим яратучы яшьләр гаиләләре белән килә. Алар – бизнесменнар. Нурулла абыйның янына да кучтәнәчсез кермиләр. Яңа ел алдыннан да табын коралар. Бабайга чыршы бизәү кирәкми, ул болай да чыршылар арасында яши бит.

Кукмара районының ике хуҗалыклы авылында яшәүче Бояр әбиләрен дә онытмадык. Янил клубы мөдире Гөлия Якуповадан хәлен сораштык. Җәен авыл үзешчәннәренең Боярга барып, концерт куя, бергәләп чәй эчә торган гадәтен беләбез. Кышын берәр нәрсә майтарырга җыенмыйлармы икән?

– Кыш көне концерт программалары белән барып булмый. Көрте бар, салкыны. Кыш бабай белән Кар кызы булып киенеп, барып котлап килсәк, әйбәт инде. Яхшы идея бу, – диде Гөлия.

«Үзем генә каршы алган юк»

Бер авылга – ике хуҗалык һәм өч кеше. Әгерҗе районындагы Чәчкә авылының бүгенге хәле шундый. Моннан өч ел элек барган идек без анда – бүген дә берни үзгәрмәгән. Йортларның берсендә – 52 яшьлек Фәнис, икенчесендә кызы белән 87 яшьлек Әнисә әби гомер кичерә.

– Бер елны да Яңа елны өйдә уздырган юк. Үземә генә күңелсез. Телевизор карап утыру туйдыра. Шуңа күрә йә дусларга, йә күрше авылга улым янына барырга тырышам. Апам Фәридә шәһәргә яшәргә китте. Чыршы бизәү дигән нәрсә юк инде ул. Авылда кеше күп булганда бизи идек, – ди Фәнис Гыйльметдинов.

Фәнис Чаллыга, Әлмәткә дә китеп яшәп караган, тик күңеле барыбер авылга тарткан. «Шәһәр кешесе түгел мин, холкыма туры килми. Ял көннәрендә нәрсә эшлисең анда? Монда, ичмаса, кулга көрәк тотарга була. Авылда саф һава сулап, тәмле чишмә суы эчеп яшәүне күпкә кыйммәтрәк дип саныйм. Үземне ялгыз хис итмим. Кабат өйләнү теләге дә юк», – ди ул.

Иртәсе сәгать 5тә үк башлана аның. Йокыдан торуга, чыра ярып, мичкә ягып җибәрә. Аннан тавыкларга ашарга сала. Ашарга да үзенә әзерлисе. Элек салатын да ясаса, хәзер алай төрләндерми. Аш, боткага да риза. Кирәк-яракны автокибет китерә. Ипи машинасы да гел йөреп тора, кирәк чакта аны олы юлга чыгып ала. Фәнис – тракторчы, шабашкага да йөргәли. Чәчү, урып-җыю вакытында да аның ярдәменнән башка булмый.

Чыршы бизәлгән, пилмән бөгелгән

Әгерҗе районының Кондызлы авылы да халкы белән мактана алмый. Анда кышын нибары дүрт йортта гына яшиләр. Әмма авыл беткән дип утырмыйлар, рәхәтләнеп бәйрәм итәләр. Әнә Ирина Ажина чыршысын күптән бизәгән инде. Күршеләре бәйрәмгә аларга җыела икән. Кунаклар чакырырга пилмәне дә, мантые да, эфлисун, бананы да әзер аның. Ирина кирәк-яракны 10 чакрым ераклыктагы Красный Бор авылына барып алган. Авылда бер кешенең дә техникасы юк, шуңа күрә җәяү йөрергә туры килә.

– Өйдә – чыршы исе. Бәйрәм кәефе бар. Барысы 400 пилмән бөктем. Кеше шактый булачак, шуңа күрә табынны мулдан әзерлим. Әлмәттән абый кайта, күршеләр керәчәк. Бергә булганда, тормыш күңелле, – ди Ирина.

Кибете, юлы, суы булмаса да, халкы авылга кул селтәми. Урман эчендәге авылның үз өстенлекләре. Кешеләре дә байлык дип табынып яшәми. Гади генә нәрсәгә дә сөенә беләләр.

– Тавыклар, кәҗәләр тотабыз. Әле менә кәҗәләр бәрәнләде. Һаман саен сөткә күрше авылга барып булмый бит. Шуңа күрә үзебез асрыйбыз. Бәрәңге, суган, яшелчәсен үстерәбез. Экологик яктан чиста ризык ашыйбыз. Автокибет атнага бер мәртәбә килә, – ди Ирина. – Красный Борда яшәсәк тә була, анда да йортыбыз бар. Тик монда рәхәтрәк. Иртә белән кар көрисең, утын кертеп, мич ягасың. Кем өчендер бу кыргый кебек тоеладыр, тик без – табигать балалары. Этне дә бәйдә тотмыйбыз, урманда йөртеп кайтабыз.

Ирина – Чаллы кызы. Тормыш иптәше Иван белән кунакка кайткан җирдән танышкан. Бергә яши башлаганнар. Ирина Мадьяр авылындагы фермада терлек караган. Тырышып эшләгән өчен колхоз йорт биргән. Тик Иванның әти-әнисе авыргач, Кондызлыга күченергә туры килгән. Бүген кызлары Петербургта прокурор булып эшли. Кызлары белән горурланып, тормышларына шөкер итеп яшиләр.

«Путинны тыңламыйча ятмыйбыз»

Буа районының Аккүл авылында кышын кеше саны биштән артмый, нибары өч хуҗалыкта гына тормыш дәвам итә. Өч бабай, бер әби, бер егет дигән сүз бу. Күрше хәлләрен морҗадан чыккан төтеннән беләләр. Мәсгудә апа белән Ансар абыйның авылга күченеп кайтуына – 15 ел.

Котлыйлар, котлыйбыз! Мәсгудә апа өчен Яңа ел әнә шундый көн. Төрле шәһәрләр, авылларда яшәүче туганнары, балалары белән рәхәтләнеп телефоннан аралаша. Бәйрәмгә әллә ни исе китми. Дини гаилә намаз укып, ил-көнгә тынычлык тели.

– Төнге сәгать 12не көтмичә, Путинның котлавын тыңламыйча йокларга ятмыйбыз. Концерт яки берәр кызыклырак кино карыйбыз. Мәсгудә берәр тәмле ризык пешерә. «Шуба» салаты ясарга яшелчәләрен әзерләп куйды иде. Кайтам дигән кешегә авылда юллар да, капкалар да ачык, – ди Ансар абый.

Табында – үрдәк һәм каз

Әтнә районының Бахтачы авылында унлап йорт бар. Халкы – күбесе өлкәннәр. Кечкенә генә булса да, заманында без – журналистларның игътибарын җәлеп иткән авыл бу. Мәктәп ябылгач, укытучы Рәмзия Хөсәенова балаларны өендә укыткан иде. Моннан ун еллар элек шушы өй-мәктәп турында газета битләренә язып чыккан идек. Мәктәп тә, клуб та юк монда. Бу юлы эш турында түгел, бәйрәм турында сораштык.

– Кечкенә авыл булсак та, бәйрәмнәрне онытмыйбыз. Урамда чыршы бизәмәсәк тә, һәр йорт түрендә тора ул. Төрле утлар җемелди, бик күңелле. Башта районга барып, Чыршы бәйрәмен карыйбыз да Яңа елны каршылыйбыз. Җылы, тыныч йортыбыздан беркая да китәсе килми. Телевизор карыйбыз, тәмлүшкәләр белән сыйланабыз. Табында һәрчак каз-үрдәк, ат итеннән ризыклар була. Элек Яңа ел геройлары булып киенеп, өйдә-нөйгә кереп, бәйрәм белән котлап йөри идек. Хәзер яшьләр алай йөрми. Алар күбрәк телефонда утыра, телевизор карый, – ди Рәмзия Хөсәенова.

Мамадыш районының Тәкәрлек авылында ялгызы яшәүче Юрий Степанов күп сөйләшергә яратмый. «Беткән авылда нәрсә булсын инде?! Бер кызык та юк. Чыршы бизәмим, кемгә дип бизим мин аны?» – дип сүзен бик кыска тотты. Үз дөньясында бикләнгән кешегә бәйрәм булды ни дә, булмады ни. Аларның беткән авылларда яшәп ятулары да күпләргә аңлашылмый, сәер кебек тоела. Бәлкем, чыршыларында аллы-гөлле утлар да янмас, әмма аларның күңелләрендә бер яктылык бар. Ул хәтта беткән авылның караңгы сукмагын яктыртырга җитә.

Сәрия МИФТАХОВА

СЫНАЛДЫК, СЫНАТМАДЫК

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА,
Татарстан Язучылар берлеге рәисе:

– Язучы Марсель Галиев, авыр заманда яшибез дигәнне туганнан бирле ишетәм инде, ди. Чыннан да шулай. Катлаулы булмаган еллар килерме – анысын әйтеп булмый. Тормыш бит ул үзе катлаулы. Аны шулай кабул итәргә кирәк тә. Туганбыз икән, без – яшәргә хөкем ителгәннәр. Шуңа күрә төшенкелеккә бирелмик, ә иң мөһиме – үзебез булып калыйк, асылыбызны югалтмыйк.

Илдус ЛОТФУЛЛИН, Казандагы беренче балалар хастаханәсенең педиатрия бүлеге мөдире, доцент:

– Шатланырлык нәрсә булмаса да, күпчелек табиблар өчен 2021 ел – коронавирусы ел ул. Чирне исән-сау кичергән кешеләр өчен шатланам.

70 яшьлек әнием коронавирус белән җиңел формада авырды, вакцинасы бар иде. Мин дә авырдым. Бәйрәм көнне мине дәвалаган коллегама чәчәк бәйләме илтеп тапшырасым килә. Авыруны җиңә алмаганнар да искә төште. Бер ай элек апам 30га да җитмәгән улын җирләде, уйда шул. Бәйрәм табыны янында әйтелә торган сүзләр булмаса да, елы шундый инде.

Елның уңай яклары да бар. Фән эшлеклесе буларак, без дөньядагы вазгыятьне күзәтергә тиеш. Хәзерге вакытта фундаменталь медицина зур адымнар белән алга китә, ай саен диярлек яңа ачышлар ясала. Фән буларак медицина үсә башлады. Гади кеше моны сизмидер, әмма бу үзгәрешләр аның тормышында да күпмедер елдан соң чагылыш табачак.

Киләсе елга баглаган өметләр, дигәннән. Мәгълүмати каналларда «сугыш» дигән тема тукталыр дип өметләнәм. Телевизордагы яңалыкларда «сугыш» дип тукып торалар. Профессиональ булдыксызлык бу! Сугыштан тормышлары җимерелеп кайткан әби-бабайларның оныклары без. Бу сүзләр – безнең өчен тыелган, табу!

«ВТ» редакциясенә киләчәк ел шатлыклар гына китерсен!

Александр ШАДРИКОВ,
Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры:

– Без быел «Экология» илкүләм проекты кысасында күп эшләр башкардык. Бу эшләр өчен 11,5 млрд сум акча бирелде. Безгә нәтиҗә кирәк.

Әле башкарасы эшләребез бик күп. Илкүләм проектлар дәвам итәчәк. Шәхси тормышка килгәндә, бу ел тыныч үтте. Шөкер, югалтулар булмады. Бик бәхетле. Мин әле дә – бала. Әти-әнием исән-сау. Һәр иртә-кич әтием шалтыратып хәлемне белешә. Минем хакта газетадан укысалар яки тапшыру карасалар, шундук элемтәгә керәләр. Әтием шунда ук нәрсәдә ялгышканымны, нәрсәне дөрес әйтмәгәнемне җиткерә. Минем өчен әти сүзе күңелгә рәхәт. Исән генә булсыннар. Бу ел сәламәтлекнең кадерен белергә өйрәтте. Якыннарым янәшәдә. Моннан да зур шатлык була алмый дип уйлыйм.

Илшат НУРИЕВ,
Арча районы башлыгы:

– Еллар авыр, дибез, ләкин аны беркемнең дә күтәреп йөргәне юк. Россиядә яшәүчеләр өчен бер елның да җиңел булганы юк. Тормыш яңа сынаулар биреп кенә тора. Пандемия белән иза чигүгә карамастан, ел начар булды, дип әйтеп булмый. Уртача, тыныч килде. Әйе, кызганыч, корылыгы белән бик нык күңелгә тиде. Еллык уңышның яртысын гына җыеп ала алдык. Без республикада иң күп ашлык җыя торган беренче өч район арасына керәбез. Быел ашлык күләме буенча республикада беренче урынга чыктык, ләкин бу – җирләребезнең күп булуы нәтиҗәсе. Моннан тыш, «Ак барс» хуҗалыгында күңелсез хәлләр килеп чыгып, 4 мең баш хайванны киметергә туры килде. Безнең өчен бу шулай ук зур борчу булды. Аңа карамастан, калган агрофирмалар, узган ел белән чагыштырганда, 4 процент үсеш белән тәмамлыйлар. Сәнәгать паркында яңа предприятиеләр ачып җибәрә алдык. Узган ел кайбер өлкәләрдә бизнесның 80 проценты тукталган булса, быел алар барысы да яңарып, этәргеч алып, көчле итеп эшләп китә алды. Алар интернет аша сәүдә итүдә шактый гына уңышка ирешеп киләләр. Гомумән, халкыбыз бик актив. Быел республикада бер генә программа да тукталмады. Барысын да эшлибез. Мәктәпләр, балалар бакчалары буенча да күрсәткечләребез яхшы. Арчада беренче тапкыр балалар бакчасында буш урыннар бар. Мондый хәлнең булганы юк иде әле. Хәзер Арчада бер мәктәп саласыбыз бар. Әгәр планлаштырылган эшләр уң булса, район үзәгендәге мәктәпләрдә икенче сменада укучы балалар бетәчәк. Мәдәният өлкәсендә дә күп төрле чаралар уздырылды. Яңа Кенәр авылында клуб төзеклэндерелде. Берничә авылда яңа клуб төзергә һәм төзекләндерергә планлаштырабыз. Шулай ук берничә китапханәгә дә ремонт кирәк.

Быел районда 25 мең квадрат метрдан артыграк йортлар төзеп тапшырдык. Социаль ипотека буенча бурычларыбызны үтәп чыга алдык. Авылларда да күп эшләр эшләнде. Шул ук вакытта киләчәккә дә планнар бар. Күпчелек авылларда су проблемасы зур. Менә шуларны да башкарып чыгасы иде. Кызганыч, 24 авылда юллар начар хәлдә. Авыл хуҗалыгы тармагында цифрлаштыруга юнәлгән яңа комплекслар сафка баса башлады. Киләсе елда бу юнәлештә дә эшне дәвам итәчәкбез.

Менә шундый эшләр белән янып яшибез. Бергә, исән-сау булганда барысын да эшләп була. Иң мөһиме – еллар имин килсен дә, сугышлар булмасын.

Илгиз ЗӘЙНИ, драматург,
«Әкият» курчак театрының сәнгать җитәкчесе:

– Театрыбызда быел 11 премьера чыкты. «SHURALE: ЯҢА ФАНТАЗИЯ» спектакле Белгород шәһәрендә узган Халыкара курчак театры фестивалендә «яңалык» номинациясендә җиңү яулады. «Адәмнәр» спектакле «Алтын битлек» Россия Милли театраль премиясендә берьюлы биш номинациядә катнаша. Тугры тамашачыларыбыз безнең белән. Якыннарым, хезмәттәшләрем сау-сәламәт! Барысы өчен дә рәхмәт!

Киләсе ел ил-көнгә кайгы-хәсрәтсез, иҗади уңышлары белән килсен, элеккеге тормышыбыз кире кайтсын иде.

Гөлүсә БАТТАЛОВА, шагыйрә:

– Елларны озатканда һәм каршы алганда никтер нәтиҗә ясау һәм планнар кору кебек эшләрне яратмыйм. Бу минем иҗат кешесе булуым белән дә бәйледер. Безнең бит атнасына биш җомга да булырга мөмкин. 2021 елда «Кесә тулы давыл» исемле китабым чыкты, улым мәктәпкә укырга керде, гаиләм, якыннарым исәнсау, Аллага мең шөкер кылырлык. Киләсе елдан иминлек көтәм – дөньяда яктылыкка һәм яхшылыкка урын күбрәк булсын иде!

Ансар хәзрәт МИФТЯХОВ,
«Мәрҗани» мәчете имамы:

– Узып баручы ел шәхсән минем өчен авыррак булды. Бик күп якын кешеләремне, дусларны, танышларны соңгы юлга озатырга туры килде. Мондый югалтулар, авырулар – безнең өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән зур сынау. Аны лаеклы рәвештә, сабыр гына уздырырга тиешбез. Киләсе ел тыныч еллардан килсен, күбрәк изге гамәлләр кылырга, гөнаһлардан ерак булып яшәргә мөмкинлек чыксын. Аллаһы Тәгалә илебезгә, дөньяга тынычлык, иминлек биреп, шушы авырулардан арындырып, сәламәт булуыбызга тәвфыйк насыйп итсен. Киләсе ел хәерле, бәрәкәтле, шатлыклы ел булсын. Аллаһы Тәгалә яңгырын да, карын да, җилен дә үз вакытында насыйп итеп, уңышларыбызны, ризыкларыбызны да мулдан кылсын.

Ләйсән ХАМАТДИНОВА, блогер
(Кукмара районы Аш-Бужи авылы):

– Шөкер, бу ел тыныч узды. Якыннарыма, туганнарыма, үзебезгә авыру тимәде. Хәер, безнең авылда да фәлән кеше коронавирус белән авырый икән дигәнне ишетмәдек. Бөтен гаиләбез, авылыбыз белән прививканың көченә ышандык. Ул безне саклады дип әйтә алам. Дөрес, бик күпләр өчен сынау-сыналу елы булды. Ул кешеләргә сабырлык телим. Шушы авыру аркасында кешегә кеше йөрми башлады. Болай да туганнар арасында салкынлык сизелә торган заман бит инде. Әнә шуңа да без вирустан куркып тормадык, әтиәни, туганнарыбыз белән аралашырга тырыштык. Дөнья куып кына яшәп булмый. Әле менә Яңа елны да ике яктан әти-әни, иремнең һәм үземнең бертуганнарымны җыеп каршы алырбыз дип торабыз. Быел зур итеп мунча салып куйдык. Арыслан елын рәхәтләнеп мунча кереп, өй киемнәреннән генә каршы аласы килә. Быелгы елыбыз өчен Аллаһы Тәгаләгә чиксез рәхмәтлебез. Гаиләбездә ике ул артыннан көтеп алынган кызыбыз Сәфинә туды. Бик рәхәт мизгелләр кичереп яшәп яту. Каенатамның бизнесы да үз көенә тәгәри. Бер юнәлешен – ирем, бер өлешен энебез алып бара. Синеке-минеке юк бездә. Үзем дә ярдәм итәргә тырышам. Әмма төп бурычым – гаиләдәге җылы учакны сүндермичә, әти-әнигә хөрмәт күрсәтеп, ирне ир итеп яшәү. Яңа елда һәр кешегә бәхет телим. Ялгызлар яр тапсын, бала көткәннәргә сабый сөяргә насыйп булсын.

Раббани НУРГАЛИЕВ, көрәшче:

– 2021 ел миңа профессиональ яктан бик күп җиңүләр китерде, билгеле бер үсеш булды. Дөнья чемпионаты, Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге уеннары, зур турнирларда яулаган җиңүләрем истә калды. 2022 елда да бу күрсәткечләрдән төшмисе иде. Тагын да яңа үрләргә ирешергә насыйп булсын дип телим. Ә Кыш бабайдан саулык-сәламәтлек һәм әтиәниемә миңа бирелгән гомердән дә озынрак гомер бир, дип сорадым.

Резидә ХӨСНЕТДИНОВА,
Балык Бистәсе районы Олы Әшнәк авыл җирлеге башлыгы:

– Яңа ел бәйрәме шунысы белән рәхәт: без барыбыз да могҗизага ышанып яшибез. Менә искесен озатырбыз да яңасы санап бетерә алмаслык яңалыклар белән килеп керер төсле. Әйбәт инде бу. Кеше һәрвакыт яхшыга өметләнеп яшәргә тиеш бит. Без дә шундый уйлар белән 2022 елга кереп барабыз. Зарланырга яратмыйбыз. Үз көнебезне үзебез күреп ятабыз. Кечкенә генә авыллар өчен шактый эшләр дә эшләнде кебек. Үзара салым акчасына юлларга өлешчә вак таш түшәдек, су насосларын алыштырдык, су торбаларында тишелгән урыннарны ямадык, резервуарларны төзекләндердек. Узган ел коронавирус афәтеннән чикләүләр булу сәбәпле, барлык чараларны ачык һавада үткәргән идек. Быелгысы җылы биналарда булгач, өлкәннәр дә күбрәк килер, күңелләрәк булыр дип язылланабыз. Сабан туе да бик күңелле булды быел. Иң мөһиме – авыл кешесенең кәефе яхшы булсын да киләчәккә ышаныч белән яшәсен. 2022 елда авырулар юкка чыгар дип өметләнеп калабыз. Яңа ел яңа шатлыклар, куанычлар гына алып килсен иде.

Айдар ШӘМСЕТДИНОВ,
Казандагы «Адымнар» күптелле белем бирү комплексы директоры:

– Быел беренче сыйныфка килүче балалар күп булды. Алар – 649. Бездә хәтта 1 С сыйныфына кадәр бар. Әти кеше буларак, олы кызым мәктәпне тәмамласа, төпчегә тәүге тапкыр укырга керде. Быел ике укучыбыз бердәм дәүләт имтиханнарыннан 100 балл туплады. Олимпиада призерларыбыз узган елдан 8гә күбрәк. Ике мәктәп буенча укучылар саны 3600дән артык. Бондаренко урамындагы татар мәктәбендә укучылар 1100дән артты. Хәзерге вакытта ул Казанда иң зур саф татар телендә белем бирүче мәктәп булып санала. Татар теленә ихтыяҗ бар. Әти-әниләр балала-

МИЛЛИ ТОРМЫШ	ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫНДА БАШКАРЫЛГАН ИҢ УҢЫШЛЫ ПРОЕКТ	СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ӨЛКӘСЕНДӘ ЕЛ ШӘХЕСЕ	ӘДӘБИЯТТА ЕЛ ШӘХЕСЕ	ЕЛНЫҢ ИҢ АКТИВ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ	ТЕАТР ӨЛКӘСЕНДӘ ЕЛ ШӘХЕСЕ
					
ХАЛЫК ИСӘБЕН АЛУ ҺӘМ ТАТАРЛАР ТОРМЫШЫНДА ШУҢА БӘЙЛЕ ВАКЫЙГАЛАР	КАЗАН МЕТРОПОЛИТЕНЫНДА «ТУГАН ТЕЛЛӘР ПОЕЗДЫ» ЙӨРИ БАШЛАВЫ	РКБ ҺӘМ РЕСПУБЛИКА БАЛАЛАР КЛИНИК ХАСТАХАНӘСЕ ТАБИБЛАРЫ	ЛИЛИЯ ГЫЙБАДУЛЛИНА	ДАМИР ИСХАКОВ	ӘЗҺӘР ШАКИРОВ

ЭСТРАДА ӨЛКӘСЕНДӘ ЕЛ ШӘХЕСЕ	СПОРТ ӨЛКӘСЕНДӘ ЕЛ ШӘХЕСЕ	МӘГАРИФ ӨЛКӘСЕНДӘ ЕЛ ШӘХЕСЕ	ЕЛ ГЕРОЕ	ИҢ АКТИВ БЛОГЕР	ЕЛ ВАКЫЙГАСЫ
ФИРДҮС ТЯМАЕВ	КАМИЛӘ ВӘЛИЕВА	АЛМАЗ ХӘМИДУЛЛИН	РӨСТӘМ НӘБИЕВ	НАЗЫЙМ ГАЛИМОВ	ИЛСӨЯ БӘДРЕТДИНОВАНЫҢ АТКАЗАНГАН АРТИСТ ИСЕМЕНӘ ЛАЕК БУЛУЫ

Ильяс БАҺАУОВ, Марат ХӘБИБУЛЛИН

ҖЫРЛАП ЯШИБЕЗ!

Безнең халык җор телле, шаян инде. «ВТ» сайтында узган сораштыру нәтиҗәләре әнә шуны күрсәтте. Укучыларыбыз ел вакыйгасы дип Илсөя Бәдретдинованың атказанган исемен алуны атады. Милли тормыштагы төп вакыйга исә җанисәп булды.

Сораштыруда барлыгы 22573 кеше катнашты. Иң кызыксыну уяткан бүлек – «Эстрада өлкәсендә ел шәхесе», анда 5205 кеше тавыш бирде. «Ел герое»н – 2316, «Иң актив блогер»ны – 2346, «Ел вакыйгасы»н 2324 кеше сайлады. Ә менә «Мәгариф өлкәсендә ел шәхесе»н билгеләүдә нибары 974 кеше катнашты. Монысы да, кызганыч, бүгенге тормышыбызның бер күрсәткече.

Үтеп барган елның үзенчәлекләрен исәпкә алып, без 12 номинация билгеләгән идек. Аларның кайсылары үтә җитди булса, кайсыларына юмор да өстәдек. Ел азагында укучыларыбызның да җиңел сулап куясы килгәндер, чөнки халык «Ел вакыйгасы» итеп Илсөя Бәдретдинованың «Татарстанның атказанган артисты» исемен алуын билгеләде, аңа 1503 кеше тавыш бирде. QR-кодлы тормыш – икенче, тарихи төзелеш – тизйөрешле М12 юлын салу өченче урында калды.

«Иң актив блогер» булып Назыйм Галимов (1195 тавыш), «Ел герое» – сәяхәтче, альпинист Рөстәм Нәбиев (1811), «Спорт өлкәсендә ел шәхесе» булып фигуралы шуучы Камилә Вәлиева (1035) танылды.

«Мәгариф өлкәсендә ел шәхесе»ндә Казанның «Унбер» лицее директоры Алмаз Хәмидуллин (433) алга чыкты. Бу җәһәттән Ниса исемле укучыбыз «Мәгарифтә башка шәхесләр дә бар иде» дигән фикер калдырган, әмма ул башка шәхесләр дигәндә кемнәрне күз уңында тотканын язарга оныткан. Сүз уңаеннан, сораштыруда «Сезнең тәкъдимнәр» дигән бүлек бар иде, тәкъдим язучы гына булмады.

«Эстрада өлкәсендә ел шәхесе» номинациясендә тавыш бирү иң кызу барганы булгандыр, мөгаен. Баштагы мәлләрдә ел шәхесе булып Сәйдә Мөхәммәтҗанова барса, соңгы көннәрдә аны 3007 тавыш белән Фирдүс Тямаев узып китте.

«Театр өлкәсендә ел шәхесе» булып Кариев театрында куелган «Сөннәтче бабай» спектаклендә Сөннәтче бабай роле өчен Әзһәр Шакиров (1002) танылды.

«Елның иң актив җәмәгать эшлеклесе» тарихчы Дамир Исхаков булды.

«Әдәбиятта ел шәхесе» булып шагыйрә Лилия Гыйбадуллина танылды. Ркаил Зәйдулла белән Марат Кәбиров аннан азга гына калышты.

«Сәламәтлек саклау өлкәсендә ел шәхесе» номинациясендә Казанның 175 нче гимназиясендә зыян күргәннәргә ашыгыч ярдәм күрсәткән Республика клиник хастаханәсе һәм Республика балалар клиник хастаханәсе табиблары танылды.

«Туган телләр елының иң уңышлы проекты» дип укучылар Казан метрополитенында «Туган телләр поезды» йөри башлавын атады.

«Милли тормышта төп вакыйга» җанисәп булды.

Киләсе елда да бергә булыйк, кадерле укучыларыбыз. Безгә сезнең һәр фикерегез кадерле. Гади кешеләрне дә сораштыру герое ясагыз, дигән фикерегезне дә мыекка чорнап куйдык. Барыгызга да сораштыруда катнашуыгыз өчен зур рәхмәтебезне белдерәбез, исәнлек-саулык, бәрәкәтле еллар телибез!

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

рын татарча укытырга тели, әмма монда мәктәп җитәкчелегенең йогынтысы, пропагандасы да зур. Мәктәптә бик кызык проектлар барлыкка килде. Әйтик, төрле илләр, милләтләр фестивале. Һәр сыйныф үзе сайлаган милләтне, дәүләтне тәкъдим итә. Сез моны «Инстаграм» сәхифәсендә дә күрә аласыз. «Адымнар»га шактый яшь укытучылар килде. Башлангыч мәктәпкә педагогия көллияте тәмамлаган 16 белгечне чакырдык. Китүче мөгаллимнәр юк. Ниһаять, Татарстан Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев ярдәме белән шәһәр читендә урнашкан, ел дәвамында эшләүче лагерь ачтык. Анда быел өч смена оештырдык. Анысы да бик куандыра. Аллага шөкер, сөенеп яшибез. Киләсе елга планнар дигәндә, кадрлар мәсьәләсе борчый. Республикада укытучыларга ихтыяҗ елдан-ел арта. Укытучыларга икешәр ставка укытырга туры килә. Шуңа күрә университет тәмамлаучы яшьләрне җәлеп итү буенча даими эш алып барабыз. Алар арасыннан иң яхшыларын сайлап алабыз. Төрле кызыксындыру чараларын кулланабыз.

Хәлим КӘРИМОВ
(Балтач районы Алан авылы):

– Дөресен генә әйткәндә, быел халык өчен сөенерлек яңалыклар булмады. Чөнки һәр яктан кысу сизәбез. Бик нык бәяләр арта, авырлык бик нык сизелә. Хөкүмәт халыкка бөтенләй диярлек булышмый. Кеше ягына карамыйлар. Әлегә халык үз тырышлыгы белән генә бара, ләкин өстән басымны бик тоябыз. Бөтен яклап караганда да бу авыл кешесе өчен бер дә яхшы түгел. Пандемиягә килгәндә, авылыбызда югалтулар булмады. Авыручылар да бик аз иде. Шунысы куанычлы. Аннан соң, ничә еллар сорап йөргән юл бераз төшәлде. Икенче елга тагын бераз булыр төсле әйтәләр. Моннан тыш авылда күпер ясадылар. Бөтен эшләгән эшләр шушы. Кызганыч, район администрациясе, авыл советы тарафыннан безнең авылга караш яхшы дип әйтә алмыйм. Нәрсә сорасак, шул юк.

Шуңа күрә киләсе елга: «Аллаһка тапшырдык!» – дип аяк атлыйбыз. Яңа ел кәефе бөтенләй юк. Хәзер кабаттан бәяләр күтәрелә башлады. Куркыталар. Шәхсән үзем киләчәктә сөенерлек хәбәрләр күрмим.

Фәрит ЯХИН, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты әдәбият белеме бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре:

– Үтеп баручы 2021 ел нинди табышлары белән куандырды дигәндә, галимнәрнең борынгы әдәби ядкәрләребезне тикшерү һәм аларның язылу тарихларын ачыклау, авторларын билгеләү, биографияләрен торгызу буенча көтелмәгән ачышларга килүен күздә тотабыз. Бу юнәлештәге фәнни эзләнүләр соңгы биш ел эчендә яңа фәнни тикшеренү юлларын эзләү, табу һәм ныгытуга бәйле алып барылды. Монда заманча хәбәрдарлык, галимнәрнең аралашу мәйданнарының интернет челтәре ярдәмендә киңәюе зур файда итте. Хаталы күзаллаулардан җәмәгатьчелекне арындыру, уку йортларына яңа белемнәрне кертү, шул рәвешле әдәби-мәдәни-тарихи-иҗтимагый аң үсешен тәэмин итү чаралары хакында да уйланырга тиеш идек.

2022 ел әдәбиятыбыз классикларының юбилейларына шулай ук бай булачак. Мине төп борчыган мәсьәләнең берсе – тарихыбызда өйрәнелмәгән, фәнни тикшеренүләрдән читтә калган ядкәрләребез шактый, хәтта әйтер идем: кузгатылмаган йөк кебек. Шуларга фәнни игътибар артсын иде! Шул юлда тырышып-тырышып эшлиселәр бар әле.

Әдәби ядкәрләрне барлаучылар һәм өйрәнеп халыкка җиткерү юлында ышанычлы эш алып баручыларыбыз да арта бара. Бигрәк тә укытучылар, инженерлар, муллалар бу авыр эшкә тартылдылар. Хәзерге интернет челтәрендә аларга, аларның ачышларын халыкка, җәмәгатьчелеккә җиткерүдә мөмкинлекләр табылыр дип өметләнәм. Цифрлаштыру елында тәбәк галимнәренең шундый бер интернет челтәре оешып алса, минемчә, яхшы булыр иде. Татар халкы һәр өлкәдә уңышка ирешеп баручылардан ул.

3 гыйнвар | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «НОВОГОДНИЙ ПАПА» 12+
07.35 Мультфильм 6+
08.00 Детский телевизионный фестиваль исполнителей татарской песни «Сәйлән-2021» 0+
09.00 «БОГАТЫРША». Мультфильм 6+
10.35 «Бу – димәк, мәхәббәт». Габделфәт Сафин 6+
11.30 «Бер сулышта». Артур Исламов һәм Эльза Заяри концерты 6+
13.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Сибирь» – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
16.00 «Тылсымлы бәйрәм мизгелләре» 6+
16.30 «Татарлар» 12+
17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
18.00 «ЯҢА ЕЛДА МИНЕМ ГАИЛӘМ». Музыкаль фильм. 1 нче серия 12+
19.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
21.30 «МОЙ ДРУГ ДЕД МОРОЗ» 12+
23.00 «Туктама, йөрәк!» Фирдүс Тямаев 6+
00.25 «Секреты татарской кухни». Актеры театр им. Качалова Елена Ряшина и Илья Славутский готовят гуся 12+
00.45 «Каравай». Кузнечная мастерская 6+
01.10 «Секреты татарской кухни». Экскурсовод Диляра Зиннурова готовит могез и татлы 12+
01.30 «Каравай». Хромка. Живая старина 6+
01.55 «Әйләнә сәхнә, әйләнә...» Театр дөньясына сәяхәт 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Татарлар» 12+
06.30 «Бөркет канатында хөрлек бар». Язучы Адлер Тимергалин турында телеочерк 6+
07.30 «Тылсымлы бәйрәм мизгелләре» 6+
08.00 «АВЫЛ ЭТЕ АКБАЙ» 6+
09.15, 18.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.15 «Күрешергә вакыт табыйк». Ил-Саф концерты 12+
12.05 «Тылсымлы бәйрәм мизгелләре» 6+
13.30 Хоккей. КХЛ чемпионаты. «Себер» (Новосибирск өлкәсе) – «Ак барс» (Казан) 6+
15.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
17.30 «Татарлар» 12+
18.50 «Яратып яшик». Раяз Фасыйхов концерты 12+
21.00 «ЯҢА ЕЛДА МИНЕМ ГАИЛӘМ». Беренче серия 12+
21.45 «КӨЛКЕ ЧЫБЫРКЫСЫ». «МУНЧА ТАШЫ» эстрада театры спектакле 16+
00.40 «Татарлар» 12+
01.05 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК» 12+
04.10 «Йөрәктән – йөрәккә». Әсхәт Хисмәт турында телеочерк (субтитрлы) 6+

1 КАНАЛ

05.00, 06.10 «СТАРИК ХОТТАБЫЧ» 0+
06.00 Новости
06.30 Фильм. «МОРОЗКО» 0+
08.00 Телеканал «Доброе утро»
10.00, 12.00 Новости (с субтитрами)
10.10 «НУ, ПОГОДИ! КАНИКУЛЫ» (S) 0+
10.50, 12.10 «ЗОЛУШКА» 0+
12.35 «ЛЕВЧИК И ВОВЧИК» (S) 16+
13.55 «Давай поженимся в Новый год!» 16+
14.45 «Угадай мелодию 1991–2021» (S) 12+
15.30 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
16.50 «ОДИН ДОМА – 2» 0+
19.00 «Сегодня вечером» (S) 16+
21.00 «Время»
21.20 «КАЗАНОВА» (S) 16+
23.15 Мировая премьера. «ВОКРУГ СВЕТА ЗА 80 ДНЕЙ» (S) 16+
00.10 «Вечерний Ургант». Лучшее (S) 16+
01.05 «Вечерний Unplugged» (S) 16+
01.50 «Наедине со всеми» 16+
02.35 «Угадай мелодию» (S) 12+
03.15 «Давай поженимся в Новый год!» 16+
03.55 «Модный приговор» 6+

РОССИЯ 1

05.05 «ГОЛУБКА» 16+
07.05 Мария Порошина, Татьяна Колганова, Дмитрий Пчела, Анатолий Лобоцкий, Евгения Нохрина. «ЧЁРНАЯ КРОВЬ» 12+
09.20 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.30 «Аншлаг и Компания» 16+
13.30 Премьера. Алёна Спивак, Леонид Кулагин, Дмитрий Блохин, Валерий Сторожик. «КУЛАГИНЫ». Финальные серии 16+
15.30 Александра Власова, Юрий Беляев, Регина Мянник, Илья Акинтьев, Сергей Жигунов. «СИДЕЛКА» 12+
20.00 Вести
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
01.45 «ЧЕЛНОЧНИЦЫ» 12+
04.30 «БАЙКИ МИТЯЯ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Хоккей. Чемпионат мира. Молодёжные сборные. 1/4 финала. Прямая трансляция из Канады
08.55, 14.15, 23.00 Новости
09.00 «Дакар – 2022» 0+
09.30 «СПОРТ ТОША». Мультсериал 0+
10.00 «БОЛЕК И ЛЁЛЕК – ИСКАТЕЛИ ПРИКЛЮЧЕНИЙ». Мультфильм 0+
10.10 «БОЛЕК И ЛЁЛЕК В ЕВРОПЕ». Мультфильм 0+
10.20 «АС ИЗ АСОВ» 12+
12.25 «БЕГЛЕЦЫ» 12+
14.20 Лыжные гонки. Кубок мира. «Тур де Ски». Масс-старт. Женщины. Прямая трансляция из Италии
15.25 Прыжки на лыжах с трамплина. «Турне 4-х трамплинов». Прямая трансляция из Австрии
16.35 Лыжные гонки. Кубок мира. «Тур де Ски». Масс-старт. Мужчины. Прямая трансляция из Италии
17.55 Хоккей. КХЛ. ЦСКА – «Авангард» (Омск). Прямая трансляция
20.20 «В ПОИСКАХ ПРИКЛЮЧЕНИЙ» 16+
22.15 Все на Матч! Прямой эфир
23.05 Футбол. Кубок Франции. 1/16 финала. «Ванн» – ПСЖ. Прямая трансляция
01.10 Волейбол. Чемпионат России «Суперлига Париматч». Мужчины. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Югра-Самотлор» (Нижневартовск) 0+
03.10 «МАЛЫШКА НА МИЛЛИОН» 16+
05.30 Матч! Парад 16+

НТВ

04.45, 08.20 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 Сергей Горобченко, Карина Разумовская, Константин Демидов. «ВЕТЕР СЕВЕРНЫЙ» 16+
12.20, 16.20 «НЕВСКИЙ» (S) 16+
19.25 Никита Панфилов. «ПЁС» (S) 16+
22.15 «25 ТОПОЛИНЫХ ЛЕТ». Юбилейный концерт группы «ИВАНУШКИ INTERNATIONAL» (S) 12+
00.35 «ЛЮБИ МЕНЯ» 12+
02.30 «ТАКСИСТКА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «ВОСПИТАНИЕ И ВЫГУЛ СОБАК И МУЖЧИН» 16+
08.30 «СЕРДЦЕ ЖЕНЩИНЫ» 16+
10.40 «НЕ ГОВОРИ МНЕ О ЛЮБВИ» 16+
14.45 «АЛМАЗНАЯ КОРОНА» 16+
19.00 «ИЩУ ТЕБЯ» 16+
00.00 «ДАВАЙТЕ ПОЗНАКОМИМСЯ» 16+
02.00 «АНЖЕЛИКА И КОРОЛЬ» 16+
03.45 Субтитры. «Настоящая Ванга» 16+

ЗВЕЗДА

04.45 «ЗА ПЯТЬ МИНУТ ДО ЯНВАРЯ» 16+
08.45 Победители Всеармейского кинофестиваля любительских короткометражных фильмов. «КАДЕТСКИЙ ВЗГЛЯД»
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.15 «Оружие Победы» 12+
09.45, 10.30, 11.20, 12.05, 13.15 «Загадки века» 12+
14.05 «Загадки века». Док сериал 12+
14.55 «Загадки века». Док. сериал 12+
15.45 «Загадки века». Док. сериал. «Нож в спину Германии» 12+
16.30 «Загадки века». Док. сериал. «Операция «Прослушка» 12+
17.20, 18.15 «Загадки века» 12+
18.20 «Загадки века». Док. сериал. «Кремль и мемуары маршала Жукова» 12+
19.10 «Загадки века». Док. сериал. «Операция «Бернхард». Фальшивомонетчики Третьего рейха» 12+
20.00 «Загадки века». Док. сериал. «Операция «Тиргартенштрассе-4» 12+
20.45 «12 СТУЛЬЕВ» 12+
00.00 «Легендарные матчи». «Кубок Канады 1987. Финал. Игра первая» 12+
03.00 «ДЕВУШКА С ХАРАКТЕРОМ» 6+
04.25 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+

4 гыйнвар | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «МОЙ ДРУГ ДЕД МОРОЗ» 12+
07.30 Мультфильмы 6+
08.00 Детский телевизионный фестиваль исполнителей татарской песни «Сәйлән-2021» 0+
09.10 Сара Садыйкованың туууына 115 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә 6+
11.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Разил Вәлиев турында телеочерк 6+
12.00 «МЕНӘ УЛ БӘХЕТ!» 6+
14.00 Финал XVI Республиканского конкурса красоты, материнства и семьи «Нечкәбил-2021». Формула семьи – наука материнства 6+
16.30 «Татарлар» 12+
17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
18.00 «ЯҢА ЕЛДА МИНЕМ ГАИЛӘМ». Музыкаль фильм. 2 нче серия 12+
19.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
21.30 «ТУР ДЕ ШАНС» 12+
23.15 «ЯҢА ЕЛДА БЕРГӘ БУЛЫЙК!» 12+
01.00 «Видеоспорт» 12+
01.25 «Секреты татарской кухни». Фитнес-тренер Тимур Бикбулатов готовит индейку 12+
01.45 «Каравай». Новый яблоневый сад творит добро 6+
02.10 «Секреты татарской кухни». Баянист Айдар Валеев готовит рыбу в молоке 12+
02.30 «Каравай». Тайный смысл народных сказок 6+
02.55 «ЯҢА ЕЛ ТӨНЕНДӘ» 12+
04.30 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
05.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Татарлар» 12+
06.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Разил Вәлиев турында телеочерк 6+
07.30 «Тылсымлы бәйрәм мизгелләре» 6+
08.00 «АВЫЛ ЭТЕ АКБАЙ». Балалар өчен спектакль 6+
09.15, 18.00 «КАЙДА СИН?» Өченче серия 12+
10.15 «Синең өчен сөюләрем». Алсу һәм Азат Фазлыевлар концерты 6+
12.00 «Гомер чишмәм». Рәсим Низамов концерты 6+
15.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
17.30 «Татарлар» 12+
18.45 «Япь-яшь килеш әле хисләрем». Разил Вәлиев 6+
21.00 «ЯҢА ЕЛДА МИНЕМ ГАИЛӘМ». Икенче серия 12+
21.50 А.Цагарелли. «ХАНУМА». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
00.40 «Татарлар» 12+
01.05 «КУНАК АШЫ – КАРА КАРШЫ, ЯКИ КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК – 2» 12+
04.40 «Йөрәктән – йөрәккә». Әмирхан Еники турында телеочерк (субтитрлы) 6+

1 КАНАЛ

05.05, 06.10 Фильм «МАРЬЯ-ИСКУСНИЦА» 0+
06.00 Новости
06.30 Фильм «ОГОНЬ, ВОДА И... МЕДНЫЕ ТРУБЫ» 0+
08.00 Телеканал «Доброе утро»
10.00, 12.00 Новости (с субтитрами)
10.10 «ЧЕБУРАШКА», «УМКА» И ДРУГИЕ» (S) 0+
10.50 Маколей Калкин. «ОДИН ДОМА» 0+
12.10 «Один дома» 0+
13.00 «Буруновбезразницы» (S) 16+
14.30 «Давай поженимся в Новый год!» 16+
15.20 «Угадай мелодию 1991–2021» (S) 12+
16.10 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
17.30 Новогодний маскарад на Первом (S) 16+
19.10 «Сегодня вечером» (S) 16+
21.00 «Время»
21.20 «КАЗАНОВА». Многосерийный фильм (S) 16+
23.10 Мировая премьера. Экранизация романа Жюля Верна «ВОКРУГ СВЕТА ЗА 80 ДНЕЙ» (S) 16+
00.10 «Вечерний Ургант». Лучшее (S) 16+
01.05 «Вечерний Unplugged» (S) 16+
01.50 «Наедине со всеми» 16+
02.35 «Угадай мелодию» (S) 12+
03.15 «Давай поженимся в Новый год!» 16+
03.55 «Модный приговор» 6+

РОССИЯ 1

05.05 «ГОЛУБКА» 16+
07.05 Мария Порошина, Татьяна Колганова. «ЧЁРНАЯ КРОВЬ» 12+
09.20 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.30 «Аншлаг и Компания» 16+
13.30 Премьера. «КУЛАГИНЫ». Финальные серии 16+
15.30 «СИДЕЛКА» 12+
20.00 Вести
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
01.45 «ЧЕЛНОЧНИЦЫ» 12+
04.30 «БАЙКИ МИТЯЯ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 21.15 Смешанные единоборства. UFC. Лучшее 16+
07.00, 08.55, 14.35, 18.55, 22.50 Новости
07.05, 11.15, 14.40, 22.15 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 «Дакар – 2022» 0+
09.30, 11.35 Теннис. Кубок ATP. Россия – Австралия. Прямая трансляция из Австралии
13.10 Лыжные гонки. Кубок мира. «Тур де Ски». Женщины. 10 км. Финал. Прямая трансляция из Италии
15.25 Прыжки на лыжах с трамплина. «Турне 4-х трамплинов». Прямая трансляция из Австрии
17.10 Лыжные гонки. Кубок мира. «Тур де Ски». Мужчины. 10 км. Финал. Прямая трансляция из Италии
18.20, 19.00 «ВОИН» 16+
22.55 Футбол. Кубок Франции. 1/16 финала. «Ланс» – «Лилль». Прямая трансляция
01.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. ЦСКА – «Автодор» (Саратов) 0+
03.00 Хоккей. Чемпионат мира. Молодёжные сборные. 1/2 финала. Прямая трансляция из Канады

НТВ

04.45 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 Сегодня
08.20 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
10.20 «Белая трость». XII Международный фестиваль (S) 0+
12.20, 16.20 «НЕВСКИЙ» (S) 16+
19.25 «ПЁС» (S) 16+
22.40 Премьера. «Земляне и друзья». Новогодний концерт (S) 12+
00.55 Андрей Соколов. «ЗАХОДИ – НЕ БОЙСЯ, ВЫХОДИ – НЕ ПЛАЧЬ...» 16+
02.30 «ТАКСИСТКА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «БЕЗОТЦОВЩИНА» 16+
08.25 «МОЛОДАЯ ЖЕНА» 16+
10.30 «ЛЮБОВЬ С ЗАКРЫТЫМИ ГЛАЗАМИ» 16+
14.45 «НИКОГДА НЕ СДАВАЙСЯ» 16+
19.00 «ПРИНЦЕССА-ЛЯГУШКА» 16+
22.55 «ЗОЛУШКА С РАЙСКОГО ОСТРОВА» 16+
00.45 «НЕУКРОТИМАЯ АНЖЕЛИКА» 16+
02.25 Субтитры. «Настоящая Ванга» 16+
05.40 «ЖЕНСКАЯ ИНТУИЦИЯ» 16+

ЗВЕЗДА

04.45 «НОВОГОДНИЙ РЕЙС» 16+
08.45 «КАДЕТСКИЙ ВЗГЛЯД»
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.15 «Улика из прошлого». «Космические войны. Трагедия Союза-11» 16+
10.05, 10.55, 11.45, 12.35, 13.15 «Улика из прошлого» 16+
13.40 «Улика из прошлого». «Невеста для маньяка. Смерть по брачному объявлению» 16+
14.30 «Улика из прошлого». «Гибель академика: загадка авиакатастрофы» 16+
15.15 «Улика из прошлого». «Двойники на службе государства» 16+
16.00 «Улика из прошлого». «Дело Осмия-187. Последняя тайна Московской Олимпиады» 16+
16.50 «Улика из прошлого». «Арал. Идеальное убийство» 16+
17.40, 18.15 «Улика из прошлого». «Диагноз – невменяемость. Убийцы знаменитостей» 16+
18.40 «Улика из прошлого». «Франция против Гитлера. Последняя тайна эскадрильи «Нормандия-Неман» 16+
19.25 «Улика из прошлого». «Капитан Пауэрс. Тайна сбитого летчика» 16+
20.10 «ОСТРОВ СОКРОВИЩ» 12+
00.00 «Легендарные матчи». «Кубок Канады 1987. Финал. Игра вторая» 12+
03.35 «БЕСПОКОЙНОЕ ХОЗЯЙСТВО» 12+
05.00 «Хроника Победы». Док. сериал 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

«София Гобәйдуллинаның заманча музыка үзәге» Казан шәһәре муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе оркестры сәнгать җитәкчесе **Закирова** Анна Семеновнага **«Татарстан Республикасының халык артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесенең реклама-мәгълүмат хезмәте башлыгы урынбасары **Исәнбәт** Ринат Празат улына **«Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Премьер» вокаль төркеме солистлары: **Зәкиев** Вадим Урал улына, **Сәйфетдинов** Руслан Мөнир улына, **Ханов** Айгиз Раел улына **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты» федераль дәүләт казна югары белем бирү мәгариф учреждениесенең криминалистика кафедрасы профессоры **Казанцев** Сергей Яковлевичка **«Татарстан Республикасының атказанган югары мәктәп хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Казан шәһәренең «П.И. Чайковский исемендәге 1 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең теория дисциплиналары, хор ансамбле, вокал укытучысы **Ахунова** Гүзәл Мансур кызына, Чаллы шәһәренең «Чишмә» халыклар дуслыгы йорты» муниципаль автоном мәдәният учреждениесенең үзешчән сәнгать коллективы җитәкчесе **Билык** Валентина Михайловнага, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең халык иҗаты методисты **Галкина** Роза Павловнага, Казан шәһәренең «2 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең виолончель классы укытучысы **Добрычева** Лалә Мингали кызына, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Үзәкләштерелгән клуб системасы – Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең 24 номерлы филиалы – Покровский Урустамак авылы мәдәният йорты директоры **Зәйдуллина** Наталья Семеновнага, «Чуракай авылы мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең китапханә хезмәте күрсәтү бүлекчәсе әйдәүче методисты **Минһаҗева** Рима Инсаф кызына, «Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсендә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры **Мифтахова** Алсу Равил кызына, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Р.Н. Нәгыймов исемендәге 1 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесе укытучысы **Насыйбуллина** Гөлшат Рәис кызына, «Чистай дәүләт тарих-архитектура һәм әдәбият музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры **Печенкин** Александр Вячеславовичка, «Түбән Каманың Салих Сәйдәшев исемендәге музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Спиридонов** Петр Петровичка, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Актаныш район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе вокалчы артисты **Хөсәенова** Лилия Илгиз кызына, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең 18 номерлы филиалы – Исергәп авылы китапханәсе әйдәүче китапханәчесе **Юсупова** Миләүшә Вахит кызына, «Заман» нәшрияты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең дизайн һәм биткә салу бүлеге җитәкчесе **Яковлева** Гүзәл Сәлим кызына **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Дәүләт янгынга каршы көрәшү хезмәте янгынга каршы көрәшү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча шартнамәле бүлекчәләре идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең хезмәтне һәм әзерләүне оештыру һәм янгын сүндерү бүлекчәсе башлыгы **Фролов** Петр Ивановичка, Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе янгын сүндерүне оештыру һәм авария-коткару эшләрен уздыру идарәсе башлыгы урынбасары, эчке хезмәт полковнигы **Шәфигуллин** Марсель Рамил улына **«Татарстан Республикасының атказанган коткаручысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАТНАШ АЗЫК, АШЛЫК САТАМ.
Йомырка салучы тавыклар өчен катнаш азык

800 сум
Адрес: Казан, Техническая урамы, 15.
Телефон:
8 (927) 049-97-06

РЕКЛАМА БУЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

БӘЙРӘМДӘ «ЮК!» ДИП ӘЙТӘ БЕЛЕГЕЗ

Артык килограммнар, баш калкыткан хроник чирләр... Көтеп алган Яңа ел яллары еш кына әнә шундый күңелсез күренешләр белән дә истә кала. Яңа ел кичен сау-сәламәт уздыруның сере нидә? Озын бәйрәм яллары табиб бусагасын таптап үтмәсен өчен, нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк?

Табиб-терапевт, гастроэнтеролог Индира ГЫЙМАЛТДИНОВА белән әлеге сорауларга җавап эзләдек.

:: Индира Мөнировна, бәйрәм көннәрендә иң актуаль булган сорауга ачыклык кертик әле. Яңа ел ялларында артык авырлык җыймас өчен, нәрсәләр эшләргә кирәк?

– Күпләр бәйрәм алдыннан үз-үзенә: «Ялლардан соң диетага утырам», – дип вәгъдә бирә. Болай эшләргә ярамый. Ник дигәндә, шул хакта уйлап, бәйрәм кичендә артыгын ашап ташлавыгыз бар. Артык килограммнар җыймас өчен, ач карынга исерткеч эчемлек эчүдән сакланыгыз. Хәмер калориягә бай булуыннан тыш, аппетитны ача, организмнан су чыгуны тоткарлый. Исерткеч эчемлек кулланган кеше күпме ашаганын да белештерми. Ашыкмыйча ашау да артык авырлыктан саклый. Баш миендә туклык хисе тусын өчен, 20 минут вакыт кирәк. Шуңа күрә ризыкны яхшылап чәйнәп, ашыкмыйча гына ашагыз. Бәйрәм ялларында көнгә 4–5 тапкыр аз-азлап ашасагыз, хәерле. Бер ашау белән икенче ашау арасында өч сәгать аерма булсын. Табын янында җыелган калорияләрне чана, чаңгы, тимераякта шуып «яндырырга» тырышыгыз.

:: Бәйрәм табыны әзерләгәндә нәрсәгә өстенлек бирергә?

– Хәзер күпләр Яңа ел табынының классик вариантыннан баш тарта. Без бит бәйрәм өстәлендә элек-электән «Тун астындагы сельдь», «Оливье» салатлары, кыздырылган каз булганга күнеккән. Хәзер исә арабызда бәйрәм табынына дигән ризыкларны парда яки томалап пешерүчеләр шактый. Болай эшләгәндә, ризык бик җиңел үзләштерелә. Гомумән, бүген дөрес туклануга күчүчеләр саны көннән-көн арта бара. Шуңа күрә хәзерге бәйрәм табыннарында әллә ни зур куркыныч сагалый дип әйтә алмыйм.

:: Өстәл белән ике арада узган бәйрәм ялларында кемнәргә үз сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга кирәк?

– Бәйрәмдә ачы-төче, кыздырылган ризык ашау эзсез югалмый. Бәйрәм чорында иң беренче чиратта ашказаны, эчәк авырулары баш калкыта. Шуңа күрә бу чорда безгә күбрәк эч авырту, сару кайнау, кикергәндә ачы су килеп тилмертү, эч кату, күңел болганудан зарланучылар мөрәҗәгать итә. Гастрит, үт куыгы белән ашказаны асты бизе ялкынсынудан тилмергән кешеләр Яңа ел ялларында аеруча сак булсын иде.

pixabay.com

БӘЙРӘМ ЯЛЛАРЫНДА ИСТӘ ТОТАСЫ КИҢӘШЛӘР

- Кайберәүләр бәйрәм алдыннан, бушанам дип, ач тора. Бу – бик зур хата. Озак вакыт ашамый торып ашаганда ашказанына икеләтә зур зыян килә. Шуңа күрә бәйрәм алдыннан тамагыгыз тук булсын.
- Кунакта хуҗалар кыстаган саен, «яхшы түгел» дип, тәлинкәгә салган бар ризыкны ашап бармагыз. «Юк» дип әйтә белегез.
- Мөмкинлек булса, кечкенә тәлинкәдән ашарга тырышыгыз. Анда салынган ризык карап торышка бик күп кебек тоелса да, чынлыкта сез бик аз күләмдә ашаячаксыз.
- Ризык янында артык озак утырып, басып, ятып торырга да киңәш итмәс идем. Үзегезгә берәр шөгыль табасызмы, биисезме, якыннарыгыз белән аралашып, йә булмаса телевизор карап ял итеп аласызмы – мөһим түгел. Иң мөһиме – өстәл яныннан вакытында китә белергә кирәк.
- Десерттан баш тартыгыз. Төнгә каршы баллы ризык ашау – организм өчен зур сынау.
- Игътибар иткәнегез бардыр: бәйрәм табыны янында, гадәттә, берәүләр сөйләгәндә, икенчеләр тыныч кына ашавын белә. Әңгәмәгә сез дә кушылыгыз. Табын янында җанлы аралашу ризык белән генә мавыгырга ирек бирмәс.
- Бәйрәм көнне дә гадәттәгечә 1,5–2 литр су эчәргә онытмагыз.

Ярма гына димә

Тары

Тары ярмасын начар экологияле зур шәһәрләрдә һәм районнарда яшәүчеләргә яратырга кирәк, чөнки аның составындагы элементлар организмдагы начар матдәләрне чыгара. Кардиологлар да авыруларга тары ярмасы ашарга киңәш итә. Тары составындагы калий йөрәк эшчәнлеген җайга сала. Шул ук вакытта ул кан басымын нормада тотарга булыша һәм кан тамырларын ныгыта.

Дөге

Дөге ярмасы чәчләрнең матурлыгы, тырнакларның ныклыгы һәм нервларның сәламәт булуы өчен мөһим булган В төркеме витаминнарына бай. Дөге составында булган Е витамины исә җыерчыклар белән көрәшә. Моннан тыш, әлеге ярма кан тамырлары белән бәйле булган авыруларны, бетчәләр барлыкка килүне кисәтү өчен әһәмиятле цинкка бай.

Карабодай

Ярмалар арасында составындагы аксым күләме буенча карабодайга тиңнәр юк. Ул бит төсе өчен әһәмиятле булган тимергә, йөрәк өчен кирәк булган калий белән магнийга бай. Карабодай артык авырлыктан да котылырга ярдәм итә. Ул йокысызлыктан интегүчеләр өчен дә файдалы. Карабодай матдәләр алмашын яхшырта. Әлеге ярманың тагын бер мөһим үзенчәлеге бар: ул өлкәннәрнең күрү сәләтен саклап калырга булыша, ягъни күз тукымасын картаюдан саклый.

Үзем сынадым

Күкерт герпестан коткара

Иренемә герпес чыгып тилмертә. Аннан котылу өчен төрле ысуллар кулланып карадым. Күптән түгел шырпы күкерте булыша дип укыган идем. Герпесның чыга гына башлаган мәлендә, шушы күкертне ваклап, иреннең кычыткан җиренә сипсәң, авырту шундук басыла. Ул урын тизрәк төзәлгән дә кебек.

АЛСУ Г. Бөгелмә

ТЕМПЕРАТУРАНЫ ТӨШЕРИМ, ДИСӘҢ...

- Әледән-әле температура күтәрелеп торганда бер чәй кашыгы укроп орлыгын 200 мл суда төнәтеп, бүлмә температурасындагы суга кушып эчәргә кирәк.
- 300 г арпаны (ячмень) кайнатып, шунын суын эчсәң, температура дарусыз да төшә.
- Чәйне дөрес пешергәндә (кайнар су белән чәйнекне чайкаткач, чәй белән 1 шакмак шикәр салырга һәм чылатырлык кына кайнар су агызып, 15–20 минут томалап төнәтергә, аннары гына кирәк кадәр су салырга) андагы шикәр чәйдә була торган котехоломинны аерып чыгара. Ул исә организмны салкын тиюдән саклый, кан тамырларын чистарта.
- 10 г нарат бөресен эмаль савытка салып, 200 мл кайнар су агызырга һәм өстен ябып, сулы кәстрүл эчендә 20–30 минут кайнатырга кирәк. Аннары шуны сөзеп, ашаганнан соң 30–40 минуттан көненә 2–3 тапкыр 0,5 стакан күләмендә эчәргә.

Белеп тор!

Колак шаулаганда укроп орлыгы ярдәмгә килә. 2 аш кашыгы укроп орлыгына ярты литр су салырга, кайнап чыга башлагач, уттан алырга, бүлмә температурасында суытырга кирәк. Әлеге төнәтмәне көнгә 100әр мл күләмендә 3–4 тапкыр эчәргә. Ул кан тамырларын яхшы чистарта, шуңа бәйле рәвештә колак шаулавы кими.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

«ВТ»ДАН – ЯҢА ЕЛ ТАБЫНЫ

Яңа елга санаулы сәгатьләр калып бара. Табын әзерләү турында алдан кайгыртырга вакытыгыз булмаса, «ВТ» хезмәткәрләренең яратып әзерли торган рецептлары сезгә ярдәмгә килер.

«ТАШБАКА» САЛАТЫ

Чулпан Гарифуллина рецепты

Салатны мөмкин булганча биек, тыгыз итеп эшләсәң, шулкадәр яхшырак. Ул катламлап ясала.

Кирәк була: тавык ите (ысланган да ярый, шулпада пешкән ак ите дә), пешкән йомырка, сыр, алма, кара җимеш, суган, майонез, гөмбә, әстерхан чикләвеге.

Тәлинкәгә аз гына майонез сылыйбыз, шуның өстенә туралган суганны җәябез. Суганның ачысы бетсен өчен аны кайнар суда пешекләп алырга да мөмкин. Суган өстенә майонез сылыйбыз да салатны катлап ясый башлыйбыз. Һәр катка майонез сылыйбыз.

1 кат: тавык ите
2 кат: алма
3 кат: гөмбә
4 кат: йомырка
5 кат: тавык ите
6 кат: каражимеш
7 кат: сыр

Сырдан соң майонез кирәкми. Салат өстен әстерхан чикләвеге белән бизисе. Табынга куяр алдыннан салат бер сәгать салкынча урында торса, яхшырак.

pixabay.com

«КРЕВЕТКАЛЫ САЛАТ»

Гөлнара Зиннәтуллина рецепты

Кирәк була: «Пармезан» сыры – 80 г, креветка – 450 г, руккола – 130 г, черри помидоры – 150 г, ярты лимон согы, тәменчә тоз, борыч, зәйтүн яки көнбагыш мае.

«Пармезан» сырын (башка төр каты сыр да ярый) юка гына телемләп, кечкенә шакмаклап турарга. Креветканы тозлы суда 15 минут пешереп алырга һәм чистартырга. Аларга руккола белән урталай буленгән чери помидорларын салып, ярты лимон согын сыгарга. Тоз, борыч һәм үсемлек мае салып болгатырга. Файдалы һәм тәмле салат әзер!

«ПАНЧО» ДЕСЕРТЫ

Лиана Мәрданова рецепты

Әлеге десерт кунакларга, аеруча балаларга бик ошаячак.

Кирәк булачак: печенье – 200 г, 33 процентлы каймак – 150 мл, эремчекле сыр – 280 г, консервланган ананас – 1 банка, шикәр пудрасы – 2 аш кашыгы. Бизәр өчен шоколад һәм чикләвек куллансагыз була.

Печеньены ваклагыз. Ананасны уртача зурлыктагы шакмакларга турагыз.

Каймакны куерганчы миксер белән туглап, эремчекле сыр салып, тагын яхшылап болгатыгыз. Әлеге массага шикәр комы салып, янә болгатырга кирәк.

Пирожныйларны аерым үтә күренмәле савытларга салырга яки зур бер торт кебек өяргә мөмкин.

Ананас, крем, печенье, кремны чиратлаштырып катламлап өябез. Десертның өстен шоколад, чикләвек, җиләкләр ярдәмендә бизәргә була.

«ИТ БӘЛЕШЕ»

Гөлгенә Шиһапова рецепты

Иң элек эчлеген әзерлибез. Бәлеш тәмле булсын өчен, төрле ит кулланган яхшы. Сыер, каз, ат итләрен, бәрәңгене турыйбыз. Эчлеккә куп итеп суган салу бәлешне тәмле итә. Тоз, борыч салып болгатабыз. Аннары камырга тотынабыз. Аның өчен бер стакан җылы сөт, ярты стакан су, 100 грамм атланмай, 2 аш кашыгы майонез кирәк. Чеметеп кенә тоз өстисе. Камырны 20 минут чамасы тоткач, бәлешне ясый башлыйбыз. Бәлеш тишелмәсен өчен, камырны табага салгач, төбендә тишек ясарга кирәк. Бәлешне газ мичендә пешерәбез. Башта 240 градуска куеп, йөзен кызартып алабыз. Аннары инде 220 градуста 2,5 сәгать пешерәбез.

Бәйрәмчә бизибез

ШАШЛЫК РЕЦЕПТЫ

Альберт Каюмов рецепты

Ат, сарык яки тавык итеннән әзерлибез. Шашлык яңа чалган иттән ике сәгатьтә дә өлгерергә мөмкин. Әгәр алдан чалынган ит булса, бер яки ярты көн алдан хәстәрен күреп куйсагыз, яхшы булыр.

2 кг иткә 100 г соя соусы, 2 чәй кашыгы аджика, 2 чәй кашыгы гәрчич, ярымбожралап туралган 1 лимон, 1 помидор, 1 баш сарымсак салып болгатып, суыткычка куярга. Тәм кергәннән соң пешереп, табынга яшел тәмләткечләр һәм яшелчәләр белән бирергә.

Белеп тор!

Теләкләр чынга ашсын!

Киләсе елдан ниләр көтәсез? Теләкләрегез тормышка ашсын өчен аларны язып куегыз. Моны елның соңгы көннәрендә яисә ел башында эшләп кую яхшы.

1. Нәрсә теләвегезне төгәл билгеләгез.
Теләгегез тормышка ашсын өчен, нәрсә теләвегезне төгәл аңларга кирәк. Ул шулкадәр көчле булырга һәм кымырҗып, күңелегезне җилкендереп торырга тиеш. Шулай булмаганда аның чынга ашуы шикле.

2. Киләчәк заманда түгел, хәзерге заманда.
Теләгегезне язганда киләчәк заманда түгел, хәзерге заманда языгыз. Мәсәлән, «Мин Казанда үзем теләгән уңайлы йорт сатып алам».

3. Башкаларга кагылырга тиеш түгел.
Үз теләкләрегезне башка кеше белән бәйләргә тырышмагыз. Мәсәлән, «Камилнең миңа өйләнүен телим» дип түгел, «Мин яраткан кешемә кияүгә чыгам» дип язуың яхшырак. Бары үзегезгә бәйле теләкләр генә теләгез.

4. Вакытын билгеләгез.
Һәрбер эш төгәллекне ярата. Вак теләкләр чынга ашсын өчен 2–3 ай вакыт та җитәр. Ә зур теләгегез чынга ашу өчен ел яки аннан да күбрәк вакыт таләп итәргә мөмкин. Шунлыктан вакыт чикләрен теләкнең зурлыгына карап билгеләсәгез яхшырак булыр.

5. Яхшы кәеф белән языгыз.
Теләкләрне кәефегез булмаганда, авырганда, эшегез тыгыз булганда язарга тырышмагыз. Алда көн бетмәгән! Позитив рухта язылган теләкләр тизрәк чынга ашачак.

6. Теләк акчага бәйле булмасын.
Әгәр нәрсә дә булса сатып алырга телисез икән, «Аны алыр өчен шуның кадәр акча телим» дип түгел, ә төгәл нәрсә теләвегезне әйтеп языгыз.

7. Сер булып калсын.
Үзегезнең план, теләкләрегез турында кемгә дә булса сөйләп йөрмәгез. Бәхет тә, теләкләр дә тынычлыкны ярата. Чөнки башкалар фикере хыял-теләкләрегездән кире кайтарып, аларның чынга ашмавына сәбәп булырга мөмкин.

КӨН ДӘ БЕР СОРАУ

УКУЧЫЛАРЫБЫЗ СОРАУЛАРЫНА ҖАВАП ЭЗЛИБЕЗ


pixabay.com

Кайбер мәсьәләләргә җавап эзләгәндә, дингә дә мөрәҗәгать итмичә чара юк. Сәхифәбезне бу юлы тулысынча укучыларыбызның сорауларына багышларга булдык. «Мәрҗани» мәчетенең икенче имамы Айморат хәзрәт ХАҖИЕВ белән бергәләп җавап эзләдек.

? Аракыны аз күләмдә генә булса да сәламәтлекне ныгыту, аяк-кулга сөртү, тамак чайкау һәм башка сихәтләндерү чарасы буларак кулланырга ярыймы?

А. ЗАКИРОВА. Казан

– Әл-хәмдү лилләәһи раббил-гааләмиин. Вәс-саләәтү вәс-сәләәмү галәә расүүлинәә мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә сахбиһии әҗмәгыйин. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә хәмерне, исерткеч эчемлекләрне тыйды. Әлбәттә, аның кушканнарын үтәп яшәргә тырышабыз. Шуңа күрә аракыны миңа табиб кушты, сәламәтлекне ныгыту, организм җылынып китсен дип эчү – динебездә тыелган гамәл. Аның яхшылыкка караганда яманлыгы күбрәк. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Аракы – бөтен бәланең, начарлыкның, бозыклыкның анасы», – ди. Аракыны кулга, үпкә тирәләренә компресс итеп кую рөхсәт ителә. Әмма эчкә кертү тыела.

? Әтием үлеп китте. Кызганыч, Аллаһы Тәгалә алдындагы барлык бурычларны да үтәп яшәде дип әйтә алмыйм. Намаз укымады, ураза тотмады. Аның өчен намаз һәм уразаларны мин башкара аламмы?

Г. ГАЛИЕВА. Арча

– Мәрхүм булган кешенең урыны оҗмахта булсын! Хәзер инде Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә, кичерүенә өметләнәсе кала. Аның урынына намаз уку да, ураза тоту да мөмкин түгел. Аллаһы Тәгалә дә фарыз гамәлләрнең һәр кешедән аерым соралачагын искәртә. Һәр кеше үзе өчен генә башкара аларны. Әмма динебездә әти-әниләребез өчен хаҗ кылу рөхсәт ителә.

? Кайбер ир-атлар хатын-кызга кул күтәрергә дә күп сорамый. Моны хәтта, дини яктан аклана, диючеләр дә бар. Чынлыкта ничек соң?

ӘЛФИНУР. Балтач

– Дөньясы шундый хәзер: ир-атлар көчсезләнә башлады. Физик яктан түгел, рухи яктан. Алар арасында хатын-кызга кул күтәрүче, кыйнаучылар да бар. Бу – көчсезлекнең иң түбән ноктасы! Мондый адымга кеше дәлилләре, сүзе бетсә бара. Ир-ат һәр гамәлен аек акыл белән кылырга тиеш. Кызганыч, мондый күренешләр бар шул. Аллаһы Тәгалә кичерсен иде. Диндә дә моңа рөхсәт юк! Пәйгамбәребез (с.г.в) дә: «Сезнең иң яхшыгыз – үзенең гаиләсенә яхшы мөнәсәбәттә булганыгыз», – дигән.

? Балага ничә яшьтән дин нигезләрен өйрәтә башларга? Әйтик, ураза тоту, намаз уку турында сөйләргә?

А. САБИРОВА. Питрәч

– Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисләре буенча, балаларны 7 яшьтән дингә өйрәтә башларга кирәк. Бу – намаз, ислам дине, Аллаһы Тәгалә турында белемнәр. Кыз балага яулык ябу мәсьәләсен дә аңлата башларга кирәк.

? Бик авыр хәлдә яшәүчеләр бар. Аларның сәдака бирергә мөмкинлекләре булмаска мөмкин, мондый очракта нишләргә?

А.ГАБДУЛЛИНА. Чаллы

– Бу очракта сәдака бирергә мөмкинлек юк дип әйтмибез. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Бер хәрефкә өйрәтү дә – сәдака. Бер елмаю да – сәдака», – дигән. Шуңа күрә белгәннәребез белән уртаклашыйк, бер-беребезгә елмаю өләшик. Бу да Аллаһы Тәгалә каршында сәдака булып саналачак. Сәдака биреп булмый икән, мохтаҗларга ярдәм итү, әби-бабайларга булышу, дога уку кебек гамәлләр башкарырга мөмкин. Аллаһы Тәгалә кабул итәр.

? Коръән ашларында һәркем сәдака өләшә. Бер караганда, алыш-биреш уйнаган кебек инде бу. Йорт хуҗасы гына сәдака бирсә, яхшырак түгелме соң?

Г. ЗИЯТДИНОВА. Биектау

– Аш үткәрү – гореф-гадәтебез, динебездәге матур бер гамәл. Сәдака өләшү – мәрхүмнәр рухына рухи азык булып барып ирешә. Бу да изге гамәлләрдән санала. Әлбәттә, сәдаканы йорт хуҗасы өләшә. Тик кем өләшсә дә, бу – хәерле гамәл. Алыш-биреш дип санарга кирәкми. Аллаһы Тәгалә кабул итсен.

? Мәһәр күләменең чиге бармы? Әйтик, мин булачак иремнән теләсә нәрсә сорый алам, һәм ул аны сатып алып бирергә тиешме?

З. РАМАЗАНОВА. Арча

– Мәһәрнең чиге юк. Әмма туташларыбыз чамадан чыкмасын иде. Мөмкинлеккә карап сорарга кирәк. Бу – килешеп эшләнә торган эш. Мәҗбүри булырга тиеш түгел ул. Мәһәрнең иң түбән хакы – 3 мең сум. «Нәрсәне дә булса алмасаң, кияүгә чыкмыйм», – дию дөрес булмас.

? Кайбер кешеләргә җен ияләшкән, диләр. Андый кешене төс-кыяфәткә карап кына белеп буламы? Шайтан-җеннән ничек коткарырга?

Б. ӘҺЛИУЛЛИНА

– Аллаһы Тәгалә сакласын, чыннан да андыйлар бар. Аларны мәҗнүн дибез. Төс-кыяфәт димәктән, аның гамәлләре, үз-үзен тотышы башкаларныкыннан аерылып торыр. Җеннәрне чыгара торган хәзрәтләребез бар. Бу очракта билгеле бер догалар, Коръән аятьләре укыла. Аллаһы Тәгалә сакласын, җен ияләшмәсен! Моның өчен махсус догалары бар. Әйтик, бәдрәфкә кергәндә «Әллаһүммә инни әгүзү бикә минәль хубси вәль хабаис» дигән доганы укырга була. Өйгә кергәндә, бисмиллабызны әйтергә онытмаска кирәк.

? Якын кешебез үлеп китте. Шул ук вакытта туган көнгә чакыру алдык. Безгә бәйрәмгә барырга ярыймы?

ЗӘРИНӘ. Казан

– Урыны оҗмахта булсын! Диндә өч көннән, дүрт көннән соң дигән чикләр юк. Иң элек кешене күмеп, урнаштыру эшләрен башкарырга кирәк. Туган көндә хәмер ризыклары, исерткеч эчемлекләр була икән, бармау хәерлерәк. Әмма якын кешегез, туганыгыз чакыра икән, туганлык җепләре өзелмәсен өчен дип, чакыруны кабул итәсез. Әмма кеше мәрхүм булганда, бәйрәмнәргә йөрми тору да ярар.

? Искергән, таушалган Коръән китабым бар. Аны ягарга рөхсәт ителәме? Гомумән, дини китапларны ничек итеп саклап тотарга?

Б. БАРИЕВ. Казан

– Коръән китапларын якмасагыз хәерле булыр. Әмма, ташлаганчы, бу гамәл дөресрәк. Хәзерге вакытта күп кенә китапханәләр, мәчетләр иске китапларны кабул итә. Тапшырырга мөмкин. Ягып, әрәм итмәгез. Кешеләргә ярдәме булыр, гыйлем нигезе булыр.

? Кешегә сәгать бүләк итәргә ярамый, диләр. Имеш, гомерен кыскартасың. Динебездә моңа аңлатма бармы?

А.КӘШИПОВА. Әтнә

– Сорауда да «имеш» сүзе бар. Бу – чынлап та, имеш-мимеш. Динебездә ырым-шырымнарга урын юк. Төрле юк-барларга ышанмыйк. Сәгать бүләк итү ярый. Гомеребез сәгать бүләк итүгә генә кайтып кала икән, фикерләвебез дөрес түгел, димәк.

? Күз тиюгә каршы талисман, бөтиләр тагып йөрү дөресме? Күз тиюдән ничек сакланырга?

АЛСУ. Чаллы

– Аларны тагып йөрү дөрес түгел. Динебездә андый күренешләр юк. Күз тиюдән саклану өчен, тәһарәтле булырга, «Фатиха», «Фәлакъ», «Нәс» сүрәләрен укырга кирәк.

? Эчмим, әмма тәмәке тартам. Диндә тәмәке тартучыга карата нинди җәза каралган?

И. ШӘКҮРОВ. Арча

– Тәмәке тарту динебездә тыелган. Ачык дәлилләр булмаса да, Коръәндә: «Үзеңнең сәламәтлегеңә зыян салу тыелды», – диелә. Җәзасын Аллаһы Тәгалә үзе генә беләдер.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

Гыйнвар аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Шим	05:53	08:13	13:33	15:21	17:18
2	Якш	05:53	08:12	13:35	15:22	17:19
3	Дүш	05:53	08:12	13:36	15:23	17:20
4	Сиш	05:52	08:12	13:37	15:24	17:21
5	Чәрш	05:52	08:11	13:38	15:26	17:23
6	Пәнҗ	05:52	08:11	13:40	15:27	17:24
7	Җом	05:52	08:10	13:41	15:29	17:25
8	Шим	05:51	08:09	13:42	15:30	17:26
9	Якш	05:51	08:09	13:44	15:32	17:27
10	Дүш	05:51	08:08	13:45	15:34	17:29
11	Сиш	05:50	08:07	13:47	15:35	17:30
12	Чәрш	05:50	08:06	13:48	15:37	17:31
13	Пәнҗ	05:49	08:05	13:50	15:39	17:33
14	Җом	05:48	08:04	13:52	15:40	17:34
15	Шим	05:48	08:03	13:53	15:42	17:36
16	Якш	05:47	08:02	13:55	15:44	17:37
17	Дүш	05:46	08:01	13:57	15:46	17:39
18	Сиш	05:45	07:59	13:58	15:48	17:40
19	Чәрш	05:44	07:58	14:00	15:50	17:42
20	Пәнҗ	05:43	07:57	14:02	15:52	17:43
21	Җом	05:42	07:55	14:04	15:54	17:45
22	Шим	05:41	07:54	14:06	15:56	17:47
23	Якш	05:40	07:52	14:08	15:58	17:48
24	Дүш	05:39	07:51	14:09	16:00	17:50
25	Сиш	05:38	07:49	14:11	16:02	17:52
26	Чәрш	05:37	07:48	14:13	16:04	17:53
27	Пәнҗ	05:36	07:46	14:15	16:06	17:55
28	Җом	05:34	07:44	14:17	16:08	17:57
29	Шим	05:33	07:43	14:19	16:10	17:59
30	Якш	05:31	07:41	14:21	16:12	18:00
31	Дүш	05:30	07:39	14:23	16:15	18:02

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

РӘХМӘТ, 2021!

Узып баручы елга йомгак ясаган чакта, аны һәркем үзенчә сыйфатлыйдыр. Без бүген «Ни хәл?» сәхифәсендә танылган шәхесләр белән 2021 елга йомгак ясадык, бусагага якынлашучы елга ниятләрне барладык.

«ИСЕМЕМ ХАЛЫК ТЕЛЕННӘН ТӨШМӘСЕН»

Фирдүс ТЯМАЕВ, Татарстанның атказанган артисты:

– 2021 ел минем өчен тетрәндергеч һәм шактый кызыклы вакыйгалары белән истә калачак. Араларында тәҗрибә һәм акыл өсти торганнары да, кәефне төшерә торганнары да булды. Кыскасы, быел «Тямаев» фамилиясе еш яңгырады. Башкортстан белән бәйле хәлләрне алсак та, «Мишәрләр, вперед!» – дигән сүземне гаеп итүчеләрне искә төшерсәк тә. Бу тискәре хәлләргә җавап биреп бардык, бирешмәдек, үзебез булып калдык. Быел Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы һәм ил күләмендә уздырылган халык исәбен алуга багышлап та шактый гына эшләр эшләнде. Милләт каршындагы бурычыбызны үтәргә, җырларыбыз, иҗатыбыз аша халыкта да ватанпәрвәрлек дигән олы хисне тәрбияләргә тырыштык. Тамашачы тарафыннан исә зур ярдәм һәм хөрмәт тойдым. Яхшыны алар, начарны, ләкин бу ел зур эшләре белән истә калачак. Яңа елда да минем исем халык теленнән төшмәсен. Әмма 2022 елда күбрәк яхшы яктан гына сөйләсеннәр иде. Киләсе елда сәхнәгә чыгуыма 10 ел була, инде хәзердән үк әлеге вакыйганы матур итеп уздырырга әзерләнәбез. Ниятләр зурдан!

«КЕЛӘМГӘ КАЙТАСЫМ КИЛӘ»

Муса ГАЛЛӘМОВ, көрәшче:

– Узып баручы елда шактый зур эшләр эшләнде, тормышыбызны үзгәрткән карарлар кылынды. Быел без гаиләм белән Лаешка күчтек, монда яңа эшкә урнаштым. Әң сөендергән вакыйга – быел мин дүртенче тапкыр эти булачагым турында белдем. Аннан соң, 2021 елның җәе Бөтенроссия татар авыллары Сабан туенда батыр исемен алуым белән истә калыр дип уйлыйм. Әлбәттә, пандемия дә читләтеп үтмәде. Әтиәниләр, туганнарым авырды, үзем исә вакцина ясаттым. Гомумән, бу елым шактый нәтиҗәле узды. Булган ниятләремне, хыялларымны чынга ашыруга таба зур адым атладым. Киләсе елга да планнар зурдан. Иң беренче чиратта, савыгып, аягымны төзәтеп, келәмгә кайтасым килә. Ә инде газета укучыларга иң мөһиме – тазалык телим. Зур максатлар куеп, шул максатларга таба атларга язсын!

«БӘХЕТНЕҢ ИСКЕСЕ ДӘ ЯРЫЙ»

Гөлназ ГЫЙНИЯТОВА, «ТНВ-Планета» телеканалы алып баручысы:

– Узып баручы ел уңышлары белән дә, авырлыклары белән дә истә калыр. Авырлыклары, беренче чиратта, әлеге дә баягы пандемиягә бәйле. Һәркемнең ишеген шакымый калмагандыр ул афәт. Югалтулар күп булды – киткәннәрнең урыннары оҗмахта булсын... Күп тапкырлар әйтелсә дә, исәнлек һәм сәламәтлек – хәзер иң мөһиме. Сау-сәламәт булып Яңа елга керү инде үзе – иң зур сөенеч. Туфан абый Миңнуллинның алтынга тиң сүзләре аеруча актуальләшә бара: «Бәхетнең аның искесе дә ярый, Яңа ел яңа кайгылар алып килмәсен». Барлык тамашачыларыма шуны телим!

«ХЫЯЛЛАНЫРГА ДА КУРКА ИДЕМ»

Динә ЗАКИРОВА, скрипкачы:

– 2021 ел тормышымда авыр елларның берсе булды. Бу, иң беренче чиратта, пандемиягә бәйле. Быел бик күп якыннарыбызны югалттык. Барысы да күңелдә. Коллегалар китте, туганнарны җирләдек. Бу авырлыклар тизрәк үтеп китсен иде дә, тыныч тормышта яши башласак иде. Әле менә үзебез дә авырып алдык, терелеп киләбез инде. 2021 ел иҗат өлкәсендә шактый нәтиҗәле булды. Февраль аенда Муса Җәлил исемендәге дәүләт бүләгенә ия булдым. Иҗатымдагы иң зур вакыйгаларның берсе, зур горурлык хисе белән әйтерлек исем. Сәнгать өлкәсендә үз юлымны сыза башлаганда, бу турыда хыялланырга да курка идем.

Быел, Аллага мең шөкер, ниятләрем тормышка ашты. Кызым беренче сыйныфка керде. Моннан тыш, театр түгәрәгенә йөри, Камал театрында ике спектакльдә катнаша – «Сагынырсызмы?» һәм «Малай, Бүре һәм Шомбай» пьесаларында уйный. Кечкенә генә рольләр булса да, бик горурланам аның белән. Гомумән, аның өчен яшим, эшлим, иҗат итәм.

Форсаттан файдаланып, «Ватаным Татарстан» газетасын укучыларның барысын да бәйрәм белән котлыйм! Тән сәламәтлеге, җан сихәте, иман байлыгыннан аермасын.

«БЫЕЛ РЕКОРД КУЙДЫК»

Айназ ГАБИДУЛЛИНА, блогер:

Юлбарыс елы килә. Барыбыз да аны зур өметләр белән көтә. Ел нинди булыр? Экстрасенс Алсу ГАЗИМҖАНОВА белән әнә шул хакта сөйләштек.

АҢАРЧЫ ГАЗЕТА УКУЧЫЛАРГА АЛСУНЫҢ 2021 ЕЛГА БИРГӘН ФАРАЗЛАРЫН ИСКӘ ТӨШЕРЕП ҮТӘБЕЗ:

– Климат үзгәрәчәк. Икътисадта киеренкелек саклана. Кризис ел буена җитәчәк. Россиянең чикләре киңәячәк. Күп кенә илләргә юллар ачылачак. Ел гаилә кору, эшкә урнашу, бала табу өчен уңай булачак. Авыл хуҗалыгы өлкәсендә зур уңышлар көтелә. Кайсы өлкәгә тотынсагыз, шунысында эшләрегез гөрләячәк. Тагын да вируска әйләнеп кайтсак, без аңа ияләнәчәкбез. Әмма хайваннарга бәйлениндидер чир чыгачак. Барысын да ачыкламыйча, аларны бетермәсеннәр иде.

ВИРУС

Без коронавирус хакында 2023 елда бөтенләй онытачакбыз. Озакламый бу авырудан үлүчеләр кимеп, ул гадәти грипп төсле генә булып калачак. Киләсе елда бавыр, эчәклек һәм ашкайнату системасы авырулары баш күтәрәчәк. Ашауга игътибар артуны күрәм. Кешеләр дөрес туклануга күчә башлаячак. Ашказаны эшкәртмәүдән интегүчеләр булачак. Итле ризыкларны азрак куллана башлаячаклар.

АВЫРУЛАР

Онкология авырулары артка чигенә. Медицинада зур үзгәрешләр булачак. Әйтик, кул чуклары, аякларны үстерә башлаячаклар. Эшләми башлаган мускуллар, сеңерләрне хәрәкәткә китерәчәкләр. Онкология авыруларын иртәрәк ачыклый башлыйлар. Үпкәләрдә үзгәрешләр барлыкка киләчәк. Бу һавадагы кристалларга бәйле булачак. Соңгы унъеллыкта кешенең үпкәләре башкача эшли башлар. Киләчәктә кешенең ДНКсында үзгәрешләр булачак.

ФАҖИГАЛӘР

Илдә сугыш булмаячак. Әмма терактлар кабатланачак әле. Акылга зәгыйфь кешеләр артыр. Суицидлар да аз булмас.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ

Мин нигәдер буш басулар күрәм. Бөтенләй ашлык булмас димим, ул уңар, әмма яңгырлар аркасында аңа зыян килер. Халык җиргә тартылыр. Яшелчәләрне үзе утыртучылар артачак.

ТУКЛАНУ

Киләсе елда кешеләрнең күбесе хәмердән һәм иттән баш тартачак. Бу агулану белән бәйле булачак. Халык ризык кадерен аңлый башлаячак.

АКЧА

Озакламый кәгазь акча бетәр төсле. Кешеләр акчаларын пирамидаларга салмасын иде. Акчаны банкта да сакларга киңәш итмим. Нәрсәдер алырга да кушасым килми. Һәр кеше үзе кирәк әйберенә тотсын. Машиналарга бәйле нидер булачак. Бәлки аларның бәяләре төшәр, бәлки сату кимер – анысы билгесез. Доллар белән евро беркая да китмәячәк. Кешеләр акчаның иң мөһим әйбер түгеллеген аңлар.

БАЛАЛАР

Юлбарыс елында бик күп сабыйлар туачак. Мин гел парлы кешеләр күрәм. Димәк, гаилә коручылар артачак. Аерылышучылар кими. Дәүләт тарафыннан гаиләләр өчен яңа түләүләр булачак.

СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘР

Тиздән кешеләр телефоннан бераз аерыла башлаячак. Соңгы арада аларны аннан аерып булмый бит. Ниндидер бер популяр социаль челтәр юкка чыгачак. Кайсы икәнен беләм, әмма әйтмим. Менә шуннан соң кешеләр чын тормышка кайтыр дип уйлыйм.

МӘГАРИФ

Озакламый мәктәптә укулар үзгәрәчәк. Дәресләр саны кимер төсле. Җәйләргә БДИда үзгәреш көтелә. Ул җиңеләя. Укытучы һәм тәрбиячеләргә хөрмәт артачак. Ел буе алар хакында сөйләячәкләр.

ҺАВА ТОРЫШЫ

Аномаль җылылык яки салкыннар күренми. Әмма температура нормадан 3–4 градуска үзгәрәчәк. Киләсе елда явым-төшем күп булачак.

БӘЙРӘМ

Яңа елны гаилә белән үткәрергә кирәк. Үз өегездә калырга тырышыгыз. Өй киемнәреннән, рәхәт итеп бәйрәм итегез. Иң мөһиме – елны дөрес тукланып башлагыз. Төн уртасында майлы, озак эшкәртелүче ризыклар ашау яхшыга түгел. Сәламәт чакта гына кәеф күтәренке. Киләчәктә озын елларның бетүен күрәм.

ЮЛБАРЫС ЕЛЫ

Фаразлар бирергә куркып тотынган идем, әмма ел әйбәт килә. Мин яктылык күрәм. Кешеләр арасында бердәмлек барлыкка килә, акыл белән эш йөртә башлаячаклар. Кешеләр, тормыштан сабак алып, матур итеп яшәячәкләр.

Гөлгенә ШИҺАПОВА
әзерләде

Юлбарыс елына йолдызнамә

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Гадәти, уңайлы урыныгыздан ел әйләнәсе чыгып-чыгып алгаларга туры киләчәк. Килеп туган хәлләр шуны таләп итәчәк чөнки. Көтелмәгән вакыйга тормышыгызга үзгәреш керткәнче, үзегез үк аны кертсәгез әйбәтрәк. Күчену, яңа шөгыльгә өйрәнү яки аралашу даирәсен алыштыру булырга мөмкин бу. Акча мәсьәләсендә кытлык көтелми.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Эшегездә чын профессионалга әйләнү мөмкинлеге ачылыр. Бу хезмәт хакыгызда бик әйбәт чагылыш табар. Шулай ук ел башында эшләрегездә ниндидер торгынлык барлыкка килгәндәй булыр. Ләкин язга таба барысы да көйләнер. Сентябрьгә чираттагы ялны планлаштыру, бу чорда сәламәтлекне кайгырту әйбәт.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Хыялланган сәяхәткә чыгу нияте чынбарлыкка әйләнер. Эш юнәлешен берникадәр үзгәртү, моның өчен курслар узу кирәк булырга мөмкин. Вируслар үзегезне читләтеп үтәр, гомумән, сәламәтлегегез тел-теш тидергесез булыр. Елның икенче яртысында тормышыгызны тагы да күркәмләндереп җибәрердәй вакыйгалар килеп чыгар.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Юлбарыс елы быелгыдан бермә-бер әйбәтрәк булыр. Зур уңышларга ирешсәгез дә, борын чөермәү хезмәттәшләрегез алдында дәрәҗәгезне генә арттырыр. Яз айларында балаларны тәрбияләү мәсьәләсендә сөеклегез белән үзара әйткәләшү-тарткалашулар булып алырга мөмкин. Әмма көтмәгәндә генә килеп туган сәеррәк хәлләр барысын да үз урынына куяр. Октябрь аенда күп акча керер, һөнәри үсешкә юл ачылыр.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Ел дәвамында көч-куәт, эчке энергия, илһам өстәлеп кенә торыр. Бу эштәге көтелмәгән кыенлыклардан бик җиңел ерып чыгарга ярдәм итәр. Хезмәтегез нәтиҗәсен шактый ук озак көтәргә туры килер. Кемнәрдер искиткеч отышлы һәм уңайлы гына итеп яшәү урынын алыштырыр. Ялгызлар арасында гаилә корып җибәрүчеләр күп булыр.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Матди хәлне ныгыту, моңарчы күрелмәгән акча керү юлларын ачу, гомумән, тормышны бөтәйтү өчен искиткеч уңышлы ел. Финанс ягының шәп булуы көзгә таба яңа торак яки кыйммәтле машина сатып алу теләге уятырга мөмкин. Моның теләктә генә калмыйча, чынбарлыкка әйләнү ихтималы бик-бик зур! Сәламәтлеккә килсәк, вак-төяк суык тидерүләрне санамаганда, барысы да әйбәт булыр.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Үлчәүләр өчен искитмәле дәрәҗәдә тыныч һәм бәрәкәтле ел. Барысының да берниндисикәлтәләрсез, бик шома гына баруы хәтта вакыт-вакыт эч пошыргыч кебек тә тоелып куяр. Бу чорда акчаның берәзлексез диярлек кереп торуы кайвакыт үзегезне бик бай кеше кебек хис итүгә хәтле китерер. Көзен яшь парлар арасында гаиләне ишәйтергә теләүчеләр күп булыр.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Чаяннарга Юлбарыс елында бик ныклап, җитди итеп эшләргә туры килер. Әйбәт кенә акча керер. Ләкин барысы да тырышлык белән генә булыр. Елның беренче яртысында бик мөһим берничә элемтә урнаштырырсыз. Бу кешеләр алга таба үзегезгә һөнәри яктан үсәргә, карьера баскычыннан күтәрелергә ярдәм итәр. Җәй ахырында тормышыгызның мәгънәсен үзегез дә көтмәгән, әмма бик яхшы якка үзгәртердәй хәлләр булыр.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Белемнәрне чарлау, яңа һөнәргә өйрәнү яки бизнес ачу өчен уңайлы ел. Күп кенә мәсьәләләрдә таныш-белешләрегез, дус-ишләрегез әйтеп бетергесез ярдәм күрсәтер. Көзгә таба ничәмә-ничә еллар буе күңелегездә йөрткән бик зур хыялыгыз тормышка ашар.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Юлбарыс елы эшне шәхси тормыштан өстенрәк куймаска өйрәтер. Чираттагы ялларны язга һәм көзгә планлаштыру хәерлерәк. Акчалы, бик мул ел. Беренчедән, төп эш урыныңда хезмәт хакыгыз артыр, икенчедән, шәп кенә өстәмә керем чыганаклары барлыкка килер. Бу хәл, әлбәттә инде, үз бәягезне арттырыр!

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Матди хәлегезне яхшырту өчен әйбәт кенә мөмкинлекләр ачылыр. Алардан, берсен генә дә кулдан ычкындырмыйча, бик оста файдаланырсыз. Елның икенче яртысында җитәкчегез җаваплы бер эш йөкләр. Икеләнмичә генә ризалашыгыз – искиткеч шәп башкарачаксыз! Сәламәтлек тә артыгын борчымас.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Ниһаять, үзегез теләгәнчә, рәхәтләнеп озын-озак сәфәр чыгу мөмкинлеге ачылыр. Яз башында яшәү урынын алыштыру планнары барлыкка килер. Карьера мәсьәләсендә ул-бу алга китеш көтелми: булганына шөкер итеп эшлисе һәм яшисе. Ел уртасында шәхси тормышыгызда куанычлы хәлләр булыр. Аларның рәхәт кайтавазы ел азагына кадәр сузылыр. Сәламәтлек тә ел дәвамында бер генә тапкыр да сынатып карамас.

ФӘНЗИЯ КАЮМОВА:

«СЕЗНЕҢ АЛДА БАШЫМНЫ ИЯМ»

Казанда яшәүче Тәлгать Каюмов хакында бер генә язмадык. Тәне пешкән 25 яшьлек егеткә ярдәм кирәклеге турындагы үтенеч хатлары интернетта йөри башлагач, без аларны эзләп таптык. Шул көннән бирле әнисе Фәнзия апа белән дә, Тәлгать белән дә аралашып торабыз. Ел ахырында алар үзләренә ярдәм күрсәткән кешеләргә газета аша рәхмәтен белдерергә дип «ВТ» журналистын кунакка чакырды.

Бу очрашу башкаларыннан аерылып торды. Ишекне ачып керүгә, мине Тәлгать үзе каршы алды. Иң элек өс киемемне элеп куйды, аннан килеп кочаклады. Әле кайчан гына урын өстендә бер хәрәкәтсез яткан егеткә үрелеп карыйсы хәзер. Ул терелеп аякка басу белән бергә, гәүдәгә дә олыгаеп киткән.

– Ике ел гомерем урын өстендә үтте. Ул көннәрне хәзер уйлыйсым да килми. Дәрес, хастаханәдә әрнүләрем озак вакыт истә булыр әле. Әмма хәзер инде тәнем төзәлгәч, барысы да әкренләп җайланып бара, – ди ул. – Тормышка карашым үзгәрде. Әмма урын өстендә яту аркасында тормыштан арттарак калдым. Хәзер башкаларны куып тотасы бар. Әйтик, шул гади генә телефонны да аңларга кирәк. Булдырырбыз аларын – баш бәласе түгел. Тик шуны белдем: иң яхшы дуслар миндә икән. Әле алай гынамы – аларның әниләренә рәхмәтлемен. Аеруча Гөлсирә апага рәхмәт. Ул безне ташламады. Аның барлык туганнары әнигә ярдәм итәргә тотынды. Алар интернетка чыгармаган булса, белмим, исән калыр идемме?

Фәнзия апаның көчле рухлы, оптимист булуына улы авырган чакта ук шаккатып кайткан идек. Исегезгә төшереп үтәбез: без барганда 1 ел да 3 ай хастаханәдә яткан Тәлгатьне әнисе өенә алып кайткан иде. Алып чыкмас та иде – ул чакта әнисен, коронавирус таралу сәбәпле, улы янына кертмәделәр. Баласын карый алмаган ана, тәвәккәлләп, улын фатирларына алып кайтты.

– Хастаханәдә улымның хәле начараюын, пешкән урыннарының төзәлмәвен белгәч, без киңәштек тә Тәлгатьне өйгә алып чыктык. Аны ашатырга кирәк, гел су сорап тора. Янында кеше тормыйча булмый иде, – дип искә ала Фәнзия апа.

Әлеге гаиләгә хакында язгач, ярдәм итәргә теләүчеләр күп булды. Фәнзия апаның картасына бер белмәгән кешеләрдән акча килеп торды. Без дә аларга ярдәм йөзеннән 50 мең сумнан артык акча җыеп тапшырдык. Бүген инде тормышлары шөкер итәрлек. Фәнзия апа пенсиягә чыккан. Тәлгать әле тернәкләнү уза. Кайчакта дуслары белән урамга да чыгып керә икән.

– Улымның дусларына чиксез рәхмәт. Алар минем өчен үлеп торалар. Тәлгатьне караган өчен рәхмәт диләр. Кайчандыр мине сүгеп ташлаучылар да булды. Янәсе, хастаханәдән чыгарып дөрес эшләмәгәнмен. Әмма йөрәгем сиздe. Ана бит мин. Күңелемне тыңладым. Аннары башка шәһәрдәге хастаханәгә салмакчылар иде. Анда да бармадык. Улым да каршы килде, мин дә. Тәлгать бик интекте. Хастаханәдә үксеп елаган чаклары булды бит аның, – ди Фәнзия апа. – Бервакыт өйдән улымның мендәр тышын алып килдем. Ышанасызмы-юкмы: шуны тәненең пешми калган күкрәк өлешенә каплагач, йоклап китәр иде. Авыруны аякка бастыру өчен зур сабырлык кирәк шул.

Фәнзия апа улы белән генә яши. Ире 38 яшендә имгәнеп, инвалид арбасына кала. Фәнзия апага аны тәрбияләр өчен бик тырышырга туры килә. Гаилә башлыгы урынга калгач, икешәр эштә эшли ул. Әмма ире генә озын гомерле булмый. Югалтуга сабыр итеп, тыныч кына яшәгәндә, улы белән булган фаҗига сыный. Фәнзия апа бирешми. Әмма шушы ике ел эчендә бик күп авыруларым баш калкытты, ди.

– Бала хакына түзәсең икән ул. Без бит бик авыр хәлдә идек. Улым авырый, минем бер тиен акчам юк. Тәлгатьнең сыйныфташларының әниләреннән кала бер кешем булмады. Аннары инде безгә бөтен Татарстан халкы ярдәм итте. Ул кешеләр алдында башымны иям, – ди Фәнзия апа. – «Ватаным Татарстан» коллективына чиксез рәхмәтлемен. Сез безне язып кына чыкмадыгыз, гел хәлебезне сорап, кулдан килгәнчә ярдәм итеп тордыгыз. Шул чакта мин ялгыз түгеллегемне аңладым.

Мәрхәмәтле кешеләр җыйган акча Тәлгатьнең яраларын эшкәртүче табибка, уколлар ясаучы шәфкать туташына түләүгә генә түгел, фатирларына ремонт ясарга да җитә. Тәлгатьне өйгә кайтаруга, алар җыелган акчага телевизор алып куйдылар. Иске тәрәзәләрне алыштыргач, фатирлары җылынды. Бер белмәгән кешеләр азык-төлек тә китерделәр. Кыскасы, бу гаиләгә гел ярдәм килеп торды. Инде хәзер Фәнзия апаның уенда бер теләк – улына яхшы килен кирәк.

– Бар борчуларны, кайгыларны иске елда калдырып, киләсе елда сөенеп яшәсәк иде. Мин елыйм да елыйм. Бу юлы кайгыдан түгел, шатлык яшьләрем түгелә. Баламның савыкканына ышанып та бетә алмыйм. Чиксез рәхмәт. Башка сүзем юк, – ди ул.

Газетада язма чыкканнан соң, безгә республиканың төрле районнарыннан шалтыраттылар. Кемдер – каз мае, берәүләр кыйммәтле кремнар, азык-төлек китерәм, диде. Хәтта Фәнзия апага шифалы дога, дару ясау өчен рецепт юллаучылар да булды. «ВТ» белән бергә булганыгыз өчен, без язган кешеләргә ярдәм иткәнегез өчен рәхмәт сезгә.

«Авыру мине үзгәртте»

30 яшьлек Данис Фәсхетдинов 7 ел янгын сүндерүче булып эшләгән. Шушы вакыт эчендә бик күпләрнең гомерен саклап калган ул. Моннан бер ел элек аның үзенә ярдәм кирәк булды. Ашказанында яман чир тапканнар егетнең. Без аның язмышын газета битләрендә бәян итеп, ярдәм итәргә тырыштык.

Ашказаны авыртып, табибларга баргач, Даниста яман чир ачыклана. Тиз арада операция кирәклеген, аннан соң химия курслары үтәргә туры киләчәген әйтәләр. Егетнең авыр хәлдә калганын ишетеп, якыннары, дуслары ярдәмгә ашыга.

Данисның бер дусты редакциягә мөрәҗәгать итте. Шулай итеп, изге эшкә газета укучыларыбыз да кушылды. «Ватаным Татарстан»дагы язманы күреп, Алсу һәм Азат Фазлыевлар бу егет өчен концерт куярга теләүләрен белдерде. Булды ул концерт. Лаеш районының Габишев бистәсендә узган чарадан җыелган акча Даниска тапшырылды. Без әле дә аның хәлен белешеп торабыз.

– Авыру тормышымны үзгәртте. Яратып эшләгән эшемнән китәргә туры килде. Табиб кушканнарны үтәп яшим. Дөрес итеп тукланырга, диета тотарга, биш вакыт намазымны калдырмаска тырышам. Үз башыңа төшсә генә сәламәтлекнең кадерен беләсең икән. Мин эшемдәге һәр кешегә рәхмәтле. Җитәкчеләрем мине авыр чакта ташламады. Химия курслары үткәндә ярдәм иттеләр. Эшем фатирлы да итте. Казаннан читтәрәк булуына да иялләштек. Үз куышым, кайтып керер җирем бар, – ди ул, сөенеп. – Мәкерле авыруны бөтенләй үк җиңдем дияргә иртәрәк әле. Әмма, шөкер, уңайландым инде. Әкренләп эшкә дә чыгармын дип торам. Аллаһы Тәгалә ташламасын. Мөмкинлектән файдаланып, миңа ярдәм иткән һәр кешегә рәхмәтемне белдерәм.

Бер җылы сүз җитә

– Иң беренче – Аллаһы Тәгалә, икенче – журналистлар! Күпме кеше язмышларын хәл итәсез бит сез! Шулкадәр җаваплы хезмәт башкарасыз. Салкында туңып үләргә ирек бирмәдегез, – дигән иде безгә Казанда яшәүче 78 яшьлек Маһинур Вилданова.

Яңа фатирга күченеп, салкынга түзә алмаганга мөрәҗәгать итте ул безгә. Баксаң, документлар җитәрлек булмау сәбәпле, газны тоташтырмаганнар икән. Тик һава торышы аңа карап тормый шул. «ВТ» хәбәрчесе, әбинең фатиры тизрәк җылынсын өчен, идарәче оешма һәм газ хезмәте белән элемтәгә керде. Укучыларыбыз да битараф калмады. Газетада язма чыккач, әбигә күчтәнәч илттеләр.

Без бу хакта язгач онытканда да идек инде. Тик Маһинур әби онытмаган икән. Берничә көн элек редакциягә үзе килеп керде ул. Кулында – бер сумка күчтәнәч, ә күзендә – яшь. Салкында туңып утырган көннәр онытылмаслык булды, ди ул.

– Мин яхшылыкны оныта торган кеше түгел. Ун ел узса да, бу хакта исемдә тотармын, рәхмәтле булырмын, – ди ул. – 36 ел иминият оешмасында эшләдем. Гомеремдә кешедән ярдәм сораганым булмады. Беркайчан да мондый хәлгә калырмын дип уйламаган идем. Әмма мин уйлаганча булып чыкмады. Фатирыма ремонт ясарга килгән ханым сезнең газетаны бирде. Мин киңәшләшергә генә шалтыраткан идем. Ул чакта миңа берәү дә ярдәм итмәде, ә сез бу эшкә алындыгыз. Рәхәт яшәгез, эшләрегез уң булсын.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ГҮЗӘЛ СӘГЫЙТОВА:

«ТАТАР ТЕЛЕН САКЛАУДА КАЗАН ҮРНӘК БУЛЫРГА ТИЕШ»

Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын нинди нәтиҗәләр белән йомгаклыйбыз? Казанда татар теленә игътибар ни дәрәҗәдә? Әлеге һәм башка мәсьәләләр хакында Казан башкарма комитеты җитәкчесенең социаль өлкә мәсьәләләре буенча урынбасары Гүзәл СӘГЫЙТОВА белән сөйләштек.

:: Гүзәл Рәмзилевна, еш кына «татар теленә урын калмаган Казан» дигәнне ишетергә туры килә. Казанда татар теле үгисетелүенең сәбәпләре нидә икән?

– «Татар теленә урын калмаган» дип әйтү – күпертү инде ул, әлбәттә. Ләкин аның нигезендә дөреслек бар. Мин башкарма комитетка эшкә килгәнче дә аңлый идем. Ул күп очракта элмә такталарга да, башка мәсьәләләргә дә бәйле. Бер караганда, элмә такталар мәсьәләсе җиңел хәл ителә кебек. Эшли башлагач, аның чишелеше алай ук гади түгеллеген һәм башкарма комитетка гына бәйле булмавын аңлыйсың. Әйтик, без Казанның Бауман урамындагы элмә такталарны тикшерергә берничә тапкыр чыктык, эшкуарлар белән аралаштык, хатлар тапшырдык. Бу эш һаман да дәвам итә. Нәтиҗәдә берничә кибет хуҗасы татарча элмә такта ясарга ризалык бирде, ләкин ул авыррак хәл ителә, чөнки кибет хуҗаларыннан өстәмә чыгымнар таләп итә торган мәсьәлә. Әгәр бу сорауга төптән алынсак, монда законга үзгәрешләр кертергә кирәк булачак. Ник дигәндә, элмә такталарны килештергәндә, архитектура идарәсе татарча язуны тәкъдим буларак кына җиткерә ала. Чөнки законда «ике телдә язылА» гына диелгән. Телләр турындагы законга «рус һәм татар телләрендә язылА» дигән ачыклык кертелсә, мәсьәлә болай катлаулы булмас иде. Бу җәһәттән хатлар әзерли башладык, аларны Марат Әхмәтов җитәкчелегендәге Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясенә, Татарстан Дәүләт Советына юлларга ниятлибез.

:: Халык яраткан проектларның берсе – Казан метросының телләр поезды киләсе елларда да йөриячәкме? Әлеге идеяне шәһәр буйлап, тукталышларда да гамәлгә ашырып булачакмы?

– Чыннан да, туган телләр поезды – тел активистлары белән берлектә уңышлы эшләнгән проектларның берсе. Депутатлар да йөрде әлеге поездда һәм сессиядә дә шушы сорау яңгырады. Яңа елдан соң да йөриячәкме бу поезд – әле төгәл генә җавап юк.

> Бу проект белән Татарстанның башка шәһәрләре дә кызыксынды, алар автобус, трамвай-троллейбусларга шушы эчтәлекне кертеп булмасмы икән дип сорау бирделәр. Без бүлешергә әзербез, чөнки ул телне пропагандалауда җиңел һәм үтемле алымнарның берсе.

Тукталышлар белән мәсьәлә авыррак тора, аның чыгымнары да зуррак. Финанс ягыннан бу үзен акламый дигән фикергә килдек. Социаль рекламага тәгаенләнгән урыннарда эшләнелсә, аны кеше азрак күрәчәк. Әлегә уйлашабыз, төрле юлларын эзлибез.

:: Бүген иң борчыганы – мәгарифнең хәле. Туган телләр елында татар мәктәпләренә, балалар бакчаларына, фәненә йогынты ясап булдымы?

– Мәгарифнең хәле һәммәбезне борчый, тик ул бүген-иртәгә генә хәл ителәсе мәсьәлә түгел. Мин Кариев театрына килгәч тә, беренче чиратта репертуарга анализ ясаган идем. Монда КФУ, Фәннәр академиясе белгечләре ярдәмендә, бакча-мәктәпләргә мониторинг эшләдек. Нәтиҗәдә татар теле укытучыларына мотивацион алымнар кирәклеге ачыкланды. Бу юнәлештә эш башланды да инде. Октябрь, ноябрь, декабрь аенда татар теле укытучылары өчен семинарлар узды. Бу семинарларны Яңа елда да дәвам итәсебез, балалар бакчалары методист-тәрбиячеләре өчен дә эшлисебез килә. Мондый интенсивлар татар мәктәпләре җитәкчеләре өчен

дә файдалы булыр иде. Җитәкчеләргә татар җанлы булу гына түгел, заманча менеджер булу да бик мөһим. Чөнки татар теленә мөнәсәбәт тә, аның мәктәптә җәелүе дә беренче чиратта җитәкчегә бәйле.

:: Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына нәтиҗәләр ясасак, нәрсәләргә ирешелде, нинди эшләр киләчәккә калды? Дәвамлы булсын дигән проектлар бармы?

– Бу елда бик күп проектлар тормышка ашырылды. Шул ук мониторинг, семинарлар, татар теле курслары. Әдәби чаралардан «Саумы, Казан» хикәяләр конкурсы, «Казан табышлары», «Сөйли торган материя» шигъри-музыкаль кичәләр, «О чем поют деревья?» спектакле, «...булу» фотокүргәзмәсе, «Итил», «Яңа Сабантуй» фестивале һәм башка проектлар. Аларның күбесен дәвамлы итәсе килә.

Чөнки дәвамлы эшнең генә мәгънәсе була. Алар нәтиҗәсендә системалы эш турында сүз йөртергә мөмкин булачак. Быел халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләүчеләргә татар теле курслары оештырылды, алдагы елда исә җәмәгать транспорты хезмәткәрләренә дә укытулар оештырасыбыз килә. Ә инде хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәрләре, башкарма комитет җитәкчеләре өчен курсларны дәвам итәргә ниятлибез. Бу курсларның кирәкле икәнен аңладык, аңа бик күп кеше кызыксынып йөрде.

Сессиядә Марат Әхмәтов Казанда татар теленә игътибар тукталмасын иде дигән теләк белдерде. Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе белән берлектә дә планнарыбыз зурдан. Мәсәлән, киләсе елдан парк-скверларда уңышлы барган «Хәрәкәттә – бәрәкәт», «Сөйлә!» проектын мәктәпләргә кертәбез. Җыеп әйткәндә, Комиссия рәисе Марат Әхмәтов әйткәнчә, Казан ул – зур мегаполис, татар теленә игътибар җәһәтеннән дә без үрнәк булырга тиеш. Чыннан да ул шулай икән. Менә мин укуда булдым, анда бөтен республикадан урынбасарлар җыелган иде. Шунда татар теле турында сүз чыккач, Гүзәл, сезне күзәтеп барабыз, сездән өйрәнәбез, дигәч, мин бик гаҗәпләндем. Миңа үзебезнең казаныбызда гына кайныйбыз, әле эшне башладык кына кебек. Алай түгел, нәтиҗәләр дә күренә башлаган икән. Бу сүзләр, әлбәттә, илһамландыра һәм тагын да зур җаваплылык өсти.

:: Казанга килгәннән бирле татар мәдәнияте, татар теленең сафлыгы өчен көрәшәсез. Кайда гына эшләсәгез дә, милли проектлар башладыгыз һәм алар барысы да дәвамлы. Татар теленә мәхәббәт гаиләдә салынганмы? Көрәшче рухы нәселдән киләме?

– Татар театрының 115 еллыгы уңаеннан Камал театры мине турыдан-туры эфирга чыгарган иде. Шунда мин татар театрының 100 еллыгына Башкортстанда чыга торган «Тулпар» журналы өчен зур мәкалә язганлыгымны, Туфан Миңнуллин, Фәрит Бикчәнтәев, Равил Шәрәфиев, Уфа «Нур» театры артистларыннан фикерләр алганымны искә төшердем. Алып баручы Фәнис Җиһанша, 15 ел элек Уфада идеңмени, дип гаҗәпләнде. Аңа мин Казанда гомер буе яшәгән кебек тоелганмын икән. Үземә дә шулай ул. Башта телевидениедә бер тормыш үткән кебек булды. Аның белән параллель рәвештә Казан консерваториясендә эшчәнлек башланды. Анда да күңел биреп эшләргә тырыштым. Аңа «Калеб» чоры килеп кушылды. «Калеб»кә Кариев театрындагы эшчәнлек өстәлде. Мин инде хәзер Казанда да өченче тормышымны үтәм кебек. Ләкин Казанга кадәр Уфа чоры булды. Анда да «Азатлык» татар яшьләре берлегендә проектлар эшләдек, хәрәкәттә булдык. Ул – холык үзенчәлегедер.

Татар теленә мәхәббәт мәктәп елларыннан ук барлыкка килде. Татар теле буенча олимпиадаларда гел беренче урын ала идем, бу фән миңа җиңел бирелә иде. Ул вакытта бәлки минем юлым шушыдыр дигән уй белән, Башкорт дәүләт университетының филология факультетындагы татар-рус бүлегенә укырга кердем. Анда Марат Шәрипов, Лилия Сәгыйдуллина, Камил Дәүләтшин, Сәгыйдулла Хафизов кебек укытучыларыбыз күңелебезгә татар әдәбиятына, мәдәниятенә тирән кызыксыну уятты. Ә инде «Азатлык» татар яшьләре берлегенә өченче курстан йөри башладым. Анда төрле чаралар үткәрә идек. Радиода эшләгән еллар да эзсез үтмәгәндер. Татар яшьләре көннәрендә теплоход белән Уфа – Казан юлларында йөрү, татар шәхесләре белән танышу, аларның уйларын күңелгә сеңдерү еллар аша ниндидер зур тойгыга әйләнде. Бәлки, ул пафослы яңгырар, ләкин мин аны миссия дип кабул иттем.

Әйтик, консерваториядә татар теле дәресләре генә укытып йөрергә дә була иде. Ләкин «Калеб» әдәбият клубы оештырдым, татар теленә, мәдәниятенә игътибарны арттырырга тырыштым. Башкарма комитетка килүем дә нәкъ әлеге миссиягә бәйле. Илсур Рәис улы эшкә чакырганда, татар юнәлешенә игътибар арттырырга кирәклеген әйтмәсә, мин бу вазыйфага алынмас идем.

> Эштә төрле чаклар була (сораулар төрледән-төрле, милли мәсьәләләр – безнең эшнең бер кечкенә өлеше), әмма мин китсәм, бу башлангычларны кем дәвам итәр дигән уй мине нинди генә очракта да биреда тота. Билгеле, бу эшне дәвам итүчеләр дә булыр, ләкин берничә елга сузылган бушлык барлыкка килүе дә бар. Әлегә мин монда кирәклегемне сизәм.

:: Шундый проектларның берсе – «Калеб». Калебләләр белән элемтә өзелмәдеме?

– «Калеб» минем тормышымда, яшьләр тормышында да зур роль уйнады дип уйлыйм. Аның барлыкка килүе дә Ходай рәхмәте кебек. Театрга килүем дә «Калеб»кә бәйле. Калебләләр белән элемтәләр, әлбәттә, саклана. Әле берничә көн элек кенә Эльмир Низамов Актерлар йортында туган көнен уздырды. Ул сәхнәдән минем, «Калеб»нең аның тормышына тәэсирен, яңа авторлар белән танышуын, яңа җырлар тууын сөйләде. Бу бик кадерле сүзләр иде. Димәк, бу еллар юкка гына узмаган. «Калеб» кичәләрен калдырмаска тырышам, шәһәр чараларына

да «Калеб»тә катнашкан, үз вакытында гонорарсыз эшләгән кешеләрне дә әкренләп җыелп итәргә тырышабыз.

:: Эш белән гаилә арасында балансны ничек сакларга? Гаиләгә вакыт каламы?

– Баланска театрда эшләгән соңгы елда игътибар бирә башлаган идем мин, ә телевидениедә эш белән генә яшәдем. Бу аңлашыла да, ул чакта гаиләм дә, балам да юк иде әле. Бу эшкә килгәч, әлеге баланс бозылды. Һәр яңа эшнең ел – ел ярымы бик авыр үтә. Беренчедән, эшнең үзенчәлегенә төшенеп җитәргә кирәк. Икенчедән, нәрсәнедер үзгәртергә теләп киләсең, ә үзгәрешләр җиңел генә бирелми. Шунысы да бар: башкарма комитетта артык уйланып, анализлап утырырга вакыт юк. Көн нон-стоп форматында уза. Бер вакыйга икенчесен, өченчесен алмаштыра. Шулай да, гаиләгә вакыт калдырырга тырышам. Нәрсә хисабынамы? Театрларга сирәгрәк йөри башладым, кичәләргә азрак йөреләә. Гаиләгә игътибарны киметәсем килми.

:: Уңышлы хатын-кызның төп таянычы кем яки нәрсә?

– Янәшәңдә аңлаучы кешең булу. Ирем аңлый, миңа ышана, гаиләнең минем өчен иң беренче урында булуын белә. Әгәр үз вакытында, бармыйсың ул эшкә, дип әйткән булса, театрга да, бу вазыйфага да алынмас идем.

:: Яңа елга теләгегез.

– Һәрбарчабызга сәламәтлек телим. Соңгы елларда бик күп кешеләрне югалттык. Кадерле кешеләр, йөрәккә якын кешеләр, милләт уллары, кызлары бакыйлыкка күчте. Үзегезне дә, якыннарыгызны да берүк саклагыз!

:: Быелгы иң зур югалту.

– Алар берничә булды. Аның берсе – Казанның 175 нче гимназиясе фаҗигасендә балаларны югалту. Мин аны шәхси фаҗига кебек кабул иттем. Эшли башлаганыма өч ай гына иде, 9 Май җиткәндә нишләптер бик нык эчем пошты. Сизелмәү булган икән... Ул көннәрне иртәдән кичкә кадәр фаҗига урынында булдык, кайбер гаиләләргә кайгылы хәбәрне дә без җиткердек, икенче көнне моргта булдым, дүрт җирләүдә катнаштым һәм минем өчен ул тормышның бәлки икегә бүлүче вакыйга да булгандыр. Чөнки әти-әнигә бала югалтудан да зуррак кайгы юктыр ул. Ә монда берничә бала һәм аларның һәрберсенең үз тарихы. Алар белән танышканда, фаҗигагә тагын да ныграк үтеп керәсең, ә без, барыбер, нечкә күңелле кешеләр. Без әле дә 175 нче гимназия фаҗигасе белән яшибез. Бу көннәрдә Ибраһимовлар гаиләсен шифаханәгә җибәрдек. Ләкин барыбер без тормыш мәшәкатьләре белән кайнап, башка юнәлешләргә кереп китәбез. Ә алар бу кайгы белән икәүдән-икәү генә калды. Бу әти-әниләрне, вакыйганы еш искә төшерәм.

Икенче тетрәндергән вакыйга Зимфира Гыйльметдинованы югалту булды. Мин әле аңа һаман да ышанып бетә алмыйм. Башкарма комитетта ике ай гына бергә эшләп калдык. Зимфира апаны күптән, телевидениедә эшләгән вакыттан ук белә идем. Ул ятим балаларга ата-аналар эзләү өчен «Әни кирәк» дигән сәхифә алып бара иде. Ул аны озак еллар алып барды.

Ул сәнгатькә, иҗат кешеләренә, яшьләргә һәрчак хәерхаһлы булды. Зимфира апа бик ярдәмчел иде. Фидакарь иде...

:: Иң зур шатлык.

– Быел үзебез дә ирем белән хастаханәдә яттык. Аннан чыккач кызымны күрү елның иң зур шатлыгы булды. Ул дәү әни-дәү әтиләрендә иде, аны алып килгәннәрен ишегалдына чыгып һәр минутны санап көтеп тордым. Эш белән бәйле шатлык – февраль аенда эшкә килеп, сессия вакытында нәрсәләр планлаштырылган иде, шуларның күбесенең тормышка ашуы. Бу – зур шатлык та, җиңеллек тә, Казан татар телле шәһәргә әйләнер дигән өмет тә.

:: Дөнья мине өйрәтте, дигән бит әле шагыйрь, быелгы ел сезне нәрсәгә өйрәтте?

– Бу ел мине көчле булырга өйрәтте. Мин аны шушы 175 нче гимназия мисалында да әйтәм. Үземне йомшак, коелып төшә торган кеше дип уйлый идем, әмма мин эмоцияләрне икенче планга куеп, үземне кулга ала белдем икән. Бу минем өчен ачыш булды. Югалып калсам, башкалар нишләргә тиеш, дисең дә алга барасың. Монда Ләйлә Ринат кызы Фазлыеваның да үрнәге сабак биргәндер. Дөнья вакытны бушка уздырмаска, берничә мәсьәләне берьюлы хәл итәргә, карарларны кичекмәстән кабул итәргә дә өйрәтте.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ЛЮЦИЯ ӘБЛИЕВА

«НАРАТ БАШЫННАН КОРЫЙ»

(ХИКӘЯ)

Ул көз ачкысыз буранны да, аяк астындагы бозлавыкны да тоймады. Баганаларның сүрән лампочкаларыннан төшкән яктылык ничә көннәр айнымаган йөзне тагын да караңгырак, тагын да ямьсезрәк итеп күрсәтте. Тик аңа барыбер иде. Керләнеп, төссезләнеп беткән шәл астындагы башында ничек тә кибет янына барып җитеп, кемнән дә булса теләнеп, тамак чылату. Һәм кинәт кенә әллә кайдан килеп чыккан яктылык шешенеп беткән күзләрне шардай ачтырып җибәрде. Бөкрәеп беткән бәләкәй генә гәүдә юл уртасына гөрселдәп барып төште.

***

Вәсимә бүген балаларын иртәрәк яткырды. Үзе ашыкпошык киендә дә урамга чыкты. Кар өстендә яткан энәне табарлык якты кич булуга карамастан, ике адым атлауга сукмактан төшеп, көрткә кереп чумды. Иренең Сәбилә белән кочаклашып-үбешеп утыруларын күз алдына китерүе дә моңа булышлык итте бугай. «Каһәр генә суксын икән!» Каргануы ире белән Сәбиләгә генә түгел, кар тулы пималарга да кагылды. «Төнгә кадәр нинди бетмәс эш ул? Баш бухгалтер дигәч тә! Икесе бергә булыр өчен сәбәп эзлиләр, каткырлары», – дип, адымнарын тизләтте. Йа Аллам! Аксак иргә дә күз атучылар булыр икән! Шул Сәбилә эшкә килгәннән бирле, ирен танып булмый, әйтерсең унсигез яшьлек егет чагы кире кайткан! Бөтенләй икенче кешегә әйләнде дә куйды. Ничә еллар ялынып та, табыннарда җырлаталмаган кешенең авызын яптырып булмый хәзер. Ата сандугач! Шул, шул... каткан тез Сәбиләнең генә эше! «Каткан тез»нең нәрсә аңлатканын белмәсә дә, әбисеннән отып калган сүзне кат-кат кабатлады: «Каткан тез! Каткан тез!»

Үзәк урамга борылгач, Вәсимә ерактан ук утлары сүнгән идарә йортын шәйләде. Иренең машинасы да күренми. «Димәк, теге себеркенең фатирда торган йортына киткәннәр! Ни җитми бу ирләргә? Ашым пешкән, баларым караулы, өй эчем ялт итеп тора. Кешедән бер ким җирем юк, төскә-мазар да төшеп калганнардан түгел. Өченче баламны әллә ашыгыбрак таптыммы соң? Ике бала белән инәкәйләргә дә сыяр идем әле», – дигән уйлар берсе-берсе белән ярышып, башында бөтерелде. Фәрихәттәйнең ишек төбенә шулкадәр ярсып килеп җитте, звонокка берәзлексез басып торганын да абайларлык дәрәҗәдә түгел иде.

– Кем бар?

– Фәрихәттәй, мин, ач әле.

Хуҗабикә ишекне ачарга ашыкмады. Сөйләшү ябык ишек аркылы дәвам итте.

– Сәбилә өйдәме?

– Юк, ул кичә үзләренә кайтып китте, әниләре чирләгән.

– Чынлапмыни, Фәрихәттәй?

– Намаздагы башым белән сиңа ялганлап торырга бала-чагамыни мин? Әйә, йомышың аңарда гына булса, хуш, сау бул, әшим, юка кофтадан гына чыктым.

Вәсимә ышаныргамы-ышанмаскамы дигәндәй, аяк астында таптанып алды. Аннан: «Фәрихәттәй, гаеп итмә инде, тыныч йокы», – диде дә капка якка атлады. Аяклары аны Рәйбәләргә каерды. Соңгы вакытта, кайчандыр бер сыйныфта укыган хатыннар якынаеп киткәннәр иде. Бала-чагасы булмаган сатучы Рәйбәнең өстәле һәрвакыт мул. Монда элек аракыны авызына якын да китермәгән Вәсимә бер-ике рюмка эчеп куя да җиңеллек ала. Рәйбәнең район үзәгендәге төзелеш оешмасында эшләгән иренең кайтмый калган чакларында, аеруча иркенләп утыралар. Ләкин Вәсимә сыйныфташына эчендә йөрткән каты төерен белгертми, авыл халкының теленә керүдән курка. Кем әйтмешли, дустан бигрәк, дошман күп. Шуларны сөендергәнче, дия дә телен аркылы тешли.

***

Зилфәт төнге уникенче яртыда кайтып кергән хатынына канәгатьсез генә карап куйды. Вәсимә: «Өйдә бөркү, балалар йоклагач, әзрәк һава алыштырып керим дип чыккан идем», – дип, чайкала-чайкала өстәл хәстәрләргә керешә.

– Кирәкми, тамагым тук. Абыйларга сугылган идем, җиңги бәлеш белән сыйлады. Эштән соң чыккач, ачыгылган иде, аларда тамак ялгадым.

– Шылтыратып әйтсәң, кешечә булыр, диденмени?

– Шылтыраттым ич. Иртәгәгә кадәр эшлисе ашыгыч эшләрем бар иде. Сабир әйтмәдемени?

– Юк.

Әллә ире ялганлый, әллә дүртенчедә укып йөргән малайлары оныткан. Вәсимә урын-җирне көйләштерә башлады.

– Миңа олы яктагы диванга җәй, әллә нигә йокы булмәсендә тыным кысыла.

Аракы исен сиздермәс өчен, иреннән ераграк булырга тырышкан Вәсимә аның каршына килеп басуын сизми дә калды. Алай гына да түгел, ничә айлар эчен күбендереп торган бөтен уйларын шәрран чыгарып салды.

– Нәрсә, законлы хатының белән йокламаска куштымыни себеркең? Аксак иргә берсенең дә чыгасы килмәгән иде, хәзер баш бухгалтер дәрәҗәсенә күтәрелгәч, теләүчеләр табылды!

Һәм китте, китте тезеп. Берсе дә калмады. Кызу канлы булмаса да, холкы кәнфит булмаган ире, култык таягы белән җиңелчә генә кундырып та, Вәсимәне туктатмады. Буа ерылган иде. Иренең үткән ел гына җир куенына кергән мәрхүм әнисе дә өлешсез калмады. Кечеләре куркып уянмаса, белмим, нишләп бетәрләр иде.

***

Зилфәт унбер ел үзләренчә бәхетле булып яшәгән гаиләне кимерә башлаган кортның көннән-көн тирәнгәрәк төшкәнен абайлый иде. Баштарак, аш-суларда бер-ике рюмка эчеп куярга гадәтләнеп киткән хатынына игътибар биреп бармады. Киресенчә: «Бөтен табынны үзенә каратып, кыстатып утырмый башлады, ичмасам», – дип сөенде генә. Берничә тапкыр эштән соң «күңелле» кайтуы да борчымады. Ә инде кичләрен юк йомышы бар итеп чыгып китеп, исереп кайта башлагач, күзләре ачылып киткән кебек булды. Баш хисапчы итеп куйгач, үзе дә эшкә башы белән чумган иде шул. Бу вакытта болай да, күнегелгән гадәт, балалар хакы дип яшәгән гаиләнең мөнәсәбәтләре катлаулана башлады. Сәбәбе кайчандыр көллияттә бергә укыган, төн йокыларыннан яздырган Сиринәнең бертуган сеңлесе Сәбиләдә генәме соң? Бәлки, арада мәхәббәт булмавыдыр? Алга тәгәрәгән гомер тәгәрмәчен уйларда гына түгел, чынбарлыкта кире кайтарып, үзгәрешләр, төзәтүләр кертергә мөмкинлек булса икән! Кырыкны ваклаган ир белән егерме биш яшьлек егетнең аермасы, ай-һай, колачларга сыймаслык!

Апасының йөз чалымнарын кабатлаган Сәбилә беренче тапкыр бухгалтерия ишеген ачып кергән мизгелдә үк, Зилфәтнең йөрәгә «мерт» итеп куйган иде. Сәбилә апасы кебек чибәр дә, тырыш, максатчан да булып чыкты. Алар еш кына икесе эштән соң калып, көндез өлгермәгән, йә булмаса, чишелеше табылмаган документлар өстендә утыра торган булып киттеләр. Хисапчы кызның бөртекләп, җиренә җиткереп эшләве Зилфәт күңеленә бәлзәм булып ятты. Сәбиләне исә баш хисапчының үз һөнәренең остасы булуы сокландырды. Шулай көн артыннан көн узып, бер ел вакыт сизелмичә дә үтеп китте. Бер кичне икәү генә калгач, Сәбилә кыенсынып кына Зилфәтнең өстәленә хат китереп салды. Башларны әйләндерерлек хушбуй исләре бөркелеп торган конвертны ачкач, хатның Сиринәдән икәнен аңлады ир...

***

«Кара син аны, үзеннән өлкән, балалы ирне аздырмаса!» – дип, Рәйбә кат-кат тел шартлатты. Тик Вәсимәгә ничә айлар йөрәгендә йөрткән серен уртаклашкач та җиңеллек килмәде.

– Сал әле тагын берне.

– Бишенче рюмка бит, күп булмасмы?

– Булмас!

Шул чак Вәсименең колагына иренең яратып җырлаган җыры ишетелә башлады. «Яшь наратлар көен җырлап киттең көмеш кыңгыраулы пар атта...»

– Рәйбә, кем җырлый?

– Кайда?

– Ишетмисеңмени, «Яшь наратлар»ны җырлыйлар ич.

< Дәвамы гыйнвар санында

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БУЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 Язылу квитанциясен безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

Җиңүче жирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, жирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

✓ мини-тракторлар;
✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Совет урамы, 42А.

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ



1 ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ

2 ОНЛАЙН: vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 атнага бер, җомга килә – 465 сум

П2409 Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә – 1000,92 сум

Реклама 16+

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ (843) 222-09-65, 222-09-70. E-mail: vtreklama@mail.ru

Газетаның киләсе саны 5 гыйнварда чыга

Баз (диал.); Ешертен сүз, хәбәр, донос; Җырчы ... Сибгатуллина; Чират; Америка теннисчысы; Агулы газ; Үзәк Америкадагы ярымутрау; Журналист ... Гыйлемханов; ... Боливар; «Форд» моделе; ... Тимер; Көньяк Америка тәвә кошы; Грек хәрефе; Сан; Терлек азыгы; Апа (диал.); Билгесез санның шартлы билгесе; Кигәвен корты; Бөркү; Бүлү; Рус эстрадасы төркеме; Кайнозой, мезозой; Җырчы Леонид ...; Виноград сорты; Кавказ халыкларында: шагыйрь-җырчы; Чаклы, кадәр (диал.)

Рәис Габдулла

Уяу, сак; Финляндиядәге күл; Йосиф Сталинның кушаматы; Туфан Миңнуллин драмасы

24 декабрь санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: портык, секанс, гүр, ләх, нутрия, илд, пыр, Әлки, Исмәй, асыл, Клин, әрәмә, Влад, аноа, чәйнек, туп, Чери, Анхель. **Вертикаль буенча:** Чили, Олег, сәрдә, күндәм, туару, Акман, әйләнеч, кәстрүл, океан, канва, ляпис, тиле, ышану, Хурал, пакь.

ВИКТОРИНА

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җаваплар-ның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 Борынгы Римда, операция вакытында авыру улсә, табибны нишләткәннәр?
А) бер тәүлек ач тотканнар;
Б) мәйдан уртасындагы «оят баганасы»на бәйләгәннәр;
В) кулларын кисканнәр.

2 Никита Хрущёвның АКШка беренче визиты ничәнче елда була?
А) 1999;
Б) 1959;
В) 2000.

3 Михаил Романов патша итеп сайланган ел.
А) 1613;
Б) 1812;
В) 1551.

4 Опричнина – ул...
А) Россиядә патшаның көчле, чикләнмәгән хакимиятенә нигезләнгән монархиячел идарә формасы;
Б) сәяси партия;
В) 1565 елда Иван IV тарафыннан ил территориясенең бер өлешендә кертелгән махсус идарә тәртибе.

Җаваплар: 1) В; 2) Б; 3) А; 4) В.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 17167 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 391

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+